• ВӘГАЗЬ •
РАМАЗАН – ГӨНАҺЛАРДАН АЕРЫЛУ АЕ
6 бит

• СОРАУ-ҖАВАП •
ТЕЛЕВИЗОР КАРАУ УРАЗАНЫ БОЗАМЫ?
7 бит

• ИМАМНЫҢ БАТЫРЛЫГЫ •
ИШМИ ИШАН ТАРИХЫ
14 бит

• НӘСЫЙХӘТ •
КОРЪӘНДӘ ИСКӘ АЛЫНГАН ХӘЕРЛЕ ГАМӘЛЛӘР
15 бит

№ 4 (285) *Татарстан мөселманнары диния нәзарәте басмасы* *шәгъбан 1440*

апрель, 2019

دين و معيشت

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

Мәрхәмәтле Рамазан ае җитә!

Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръән аятьләре булганлыктан, басмага игътибарлы булыгыз!

12+

Казанда узачак «Russia Halal Expo» күргәзмәсендә 85 экспонент катнашу теләген белдергән

9 апрель көнне «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында хәләл сәнәгатенең Халыкара «Russia Halal Expo – 2019» күргәзмәсен оештыру һәм үткәрү мәсьәләләренә багышланган матбугат конференциясе уздырылды. Очрашуда Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе урынбасары Инсаф Галиев һәм ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хәләл» стандарты буенча комитеты рәисе киңәшчесе, күргәзмәнең оештыру комитеты җитәкчесе Айрат Касыймов катнашты.

Инсаф Галиев матбугат чаралары вәкилләрен сәламләп, XI Халыкара «Россия – Ислам дөньясы: KazanSummit 2019» икътисади саммиты кысаларында узачак «Russia Halal Expo – 2019» быел тәүге тапкыр «Kazan Expo» Халыкара күргәзмәләр үзәгендә эшләячәк, дип белдерде. Спикер сүзләренә караганда, экспозициянең гомуми мәйданы 3,5 мәртәбәгә киңәеп, 5 мең кв.м.ны тәшкил итәчәк. «Russia Halal Expo – 2019» кысаларында 60 лап чара, шул исәптән белем бирү сессияләре, мастер-класслар, фикер алышу мәйдан-чыклары, оештыру күздә тотыла. Күргәзмәнең быел РФ Авыл хуҗалыгы министрлыгы ярдәме белән уздырылуын да билгеләп үтәргә кирәк.

«Хәләл сәнәгатенең үсеш тенденциясе югары, – дип билгеләп үтте Инсаф Галиев. – Әйтик, өч ел элек экспонентларның күпчелеге азык-төлек продукциясен тәкъдим итсә, бүген күргәзмә киң тармаклы - хәләл туризм, мода, финанслар, иминият, IT, медицина һәм башка юнәлешләрне берләштерә».

Күргәзмәнең эчтәлеге генә түгел, анда катнашучыларның географиясе дә шактый киңәйгән.

«Хәзерге вакытка күргәзмәдә 85 экспонент катнашу теләген белдерде, - диде Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе урынбасары. – 10 ил катнашачагын төгәл раслады. Мисал өчен, былтыр күргәзмәдә 7 ил катнашты. Моннан тыш, быел Россия төбәкләреннән катнашучылар санын арттырырга ниятлибез», - дип билгеләп үтте Инсаф Галиев.

■ dum.rt

Чаллыда Диния нәзарәте кубогына көрәш турнирлары үткәрелде

30 март көнне Чаллыда Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте кубогына татарча көрәш һәм кул көрәше буенча XI Бөтенроссия берләштерелгән турниры төгәлләнде.

Ярышларның гомуми нәтиҗәләре буенча командалар арасында төп җиңүче һәм Диния нәзарәте кубогы иясе булып Яр Чаллы командасы танылды. Икенче урында - Әлмәт районы. Өченче урынны исә Оренбург өлкәсе һәм Татарстанның Саба районы командалары үзара бүлеште.

Җирәбә нәтиҗәләре буенча турнирның төп бүләге - хаҗга юлламаны 18 яшьлек Чаллы егете Данил Хәйриев отты. Ул милли көрәш буенча 80 кг үлчәү категориясендә I урынны яулады. Төп бүләкне аңа Татарстанда хаҗны оештыру буенча рәсми оператор «ДУМ РТ Хаҗ» вәкиле Илдус Сабитов тапшырды.

Бүгенге көндә Данил Хәйриев – Яр Чаллы политехник көллиятенең чыгарылыш курс студенты. Милли көрәш белән дүртенче ел шөгыльләнә. Намазга 14 яшендә баскан. «Мин, һичшиксез, бик шат. Һаман да төп бүләкне отуыма күңел ышанмый», – дип, кичерешләре белән уртаклашты булачак хаҗи.

Хаҗга юллама һәр спорт төре буенча үз авырлык категорияләрендә җиңүче дип табылган спортчылар арасында җирәбә уздыру нәтиҗәсендә уйнатылды. Ярышларда Татарстан шәһәрләреннән һәм районнарыннан, шулай ук Башкортстан, Удмуртия республикаларыннан, Оренбург һәм Самара өлкәләреннән барлыгы 68 көрәшче һәм 38 армрестлер көч сынашты. Турнирга кадәр аларның һәммәсе намаз уку тәртибен белү буенча тест узды.

■ dum.rt

Рамазан ае алдыннан Буада Казыйлар шурасы утырышы узды

8 апрель көнне Буа районында Казыйлар шурасының чираттагы күчмә утырышы уздырылды. Республиканың баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев җитәкчелегендә үткән әлеге утырышта Татарстанда Рамазан аен үткәрүгә кагылышлы аерым карарлар кабул ителде.

Әйтик, казыйлар ураза башлану көнен, республика мәчетләрендә беренче тәравих намазын уку тәртибен, фитыр, фидия садакалары һәм зәкят нисабының минималь күләмен билгеләде.

Моннан тыш, күчмә утырыш кысаларында казыйлар Буа мәдрәсәсе шәкертләре һәм авыл имамнары белән очрашты.

■ dum.rt

Республикада балалар арасында намаз уку бәйгеләре дәвам итә

Татарстан мөхтәсибәтләрендә балалар арасында намаз уку буенча бәйгеләр дәвам итә. Шуларның берсе 15 апрельдә Алабуга шәһәренең «Әҗмәл» мәчетендә үтте. Анда 12 яшькә кадәрге 60 тан артык бала катнашты.

Бәйгедә катнашучыларга һәм кунакларга сәламләү сүзләре белән Алабуга шәһәре һәм районы имам-мөхтәсибе Хәлим хәзрәт Шәмсетдинов мөрәҗәгать итте. «Намаз – динебездә фарыз булып йөкләтелгән иң әһәмиятле гыйбадәт төрләренең берсе. Шуңа балаларны намаз укуга кечкенәдән гадәтләндерү тиешле – бу әти-әниләрнең бурычы. Балаларда намазга мәхәббәт тәрбияләү исә бүгенге бәйгенең төп максаты», – дип билгеләп узды ул.

Бәйге кызлар һәм малайлар арасында өч номинациядә аерым үткәрелде: мәктәпкәчә яшьтәгеләр һәм 1-2 нче сыйныф укучылары, 3-4 нче сыйныф, шулай ук 5-6 нчы сыйныф укучылары арасында. Катнашучыларның белемнәрен мөгаллимнәрдән һәм имамнардан торган тиешле әзерлекле жюри бәяләде. Абыйлы-энеле Ясин һәм Ямин Хәйдәровлар – мөхтәсибәт уздыра торган бу төр бәйгеләрдә даими катнашучылар. Алар бер намазны да калдырмыйлар, аның барлык таләпләрен үтиләр. Ә 4 яшьлек Госман Усманов намазны әтисе Ринат артыннан кабатлап өйрәнгән. Сабый хөкемдарларның күңелен яулады. Тавышы да, намазның барлык кагыйдәләрен төгәл итеп үтәве дә башкалардан аерылып торды.

Җиңүчеләрне ачыклаганда намаздагы хәрәкәтләрнең дөреслеге, аны үтәү тәртибе, аеруча Кәламе Шәриф сүрәләрен дөрес итеп уку исәпкә алынды. Балалар намаз укып күрсәттеләр, шулай ук жюриның теоретик сорауларына җавап бирделәр. Бәйге ахырында җиңүчеләргә һәм призлы урыннар яулаучыларга һәр номинациядә дипломнар һәм бүләкләр тапшырылды. Барлык катнашучылар да сертификатларга ия булды.

Балалар арасында намаз уку буенча район күләмендә оештырылган бәйгеләрнең чираттагысы Бөгелмәнең Үзәк мәчетендә дә үтте. Анда 30га якын бала катнашты. Бәйге шулай ук өч номинациядә малайлар һәм кызлар арасында аерым уздырылды. Шунысы сөенечле: анда «Фәтихә» мәчете каршындагы иртә үсеш төркеменә йөрүче мәктәпкәчә яшьтәге сабыйлар актив катнашты. Иң кечкенә конкурсантка нибары 3 яшь иде.

Бөгелмә шәһәре һәм районы имам-мөхтәсибе Рамил хәзрәт Хөснетдинов билгеләп узганча, балигъ булмаганнарга намаз уку фарыз булмаса да, балаларга намаз уку күнекмәләрен хәзер үк төшендерә башларга кирәк, чөнки вакыты җиткәч, һәр мөселман намазны дөрес итеп укый белергә тиеш.

Бәйгедә катнашучылар иң элек намаз укый белүләрен күрсәтте, аннары жюри әгъзаларының өстәмә сораулары на җавап бирде. Гомуми нәтиҗәләр буенча абсолют җиңүчеләр булып Әмир Таһиров, Сумая Шәмсетдинова һәм Ләйлә Андреева табылды. Призерлар арасында – Камаль Низамов, Ибраһим Мәһдиев, Ралия Вәлиева, Айнур Лотфуллин. Җиңүчеләргә һәм призерларга кыймәтле бүләкләр тапшырылды. Чара аш мәҗлесе белән төгәлләнде.

Искәртеп узыйк: намаз уку бәйгеләре ТР мөселманнары Диния нәзарәте һәм мөхтәсибәтләр тарафыннан үсеп килүче буында динебезгә, намаз укуга һәм Коръәнне өйрәнүгә кызыксыну һәм мәхәббәт уяту максатыннан үткәрелә.

■ **dum.rt**

«Зәкят» фонды сабыйларга бәйрәм оештырды

2 апрель көнендә бөтен дөньяда Аутизм проблемасы турында мәгълүмат тарату көне билгеләп үтелә. Шул уңайдан, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды «Туган авылым» күңел ачу комплексында үсешләрендә үзенчәлекләре булган балалар һәм аларның әти-әниләре өчен «Әйдәгез дуслашыйк!» дип исемләнгән бәйрәм оештырды. Анда 150дән артык кеше катнашты.

«Зәкят» хәйрия фонды генераль директоры Булат Мәрданов сүзләренә караганда, мондый чараларны оештыру тирә-юньдәгеләргә аутизм турында мәгълүмат ирештерү өчен генә түгел, ә бу проблема белән күзгә-күз очрашкан гаиләләрне берләштерү, аларга теләктәшлек күрсәтү өчен дә кирәк. Моннан тыш, ул бәйрәмне оештырырга ярдәм иткән барлык иганәчеләргә һәм мәрхәмәтле кешеләргә рәхмәт белдерде.

Бәйрәм күккә йөзләгән зәңгәр шар җибәрү белән башланып китте. Зәңгәр төс аутизм символы булып санала. Алга таба кунакларны кызыклы программа көтте. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: чара кысаларында шулай ук табиблар, үзенчәлекле балалар белән эшләүче белгечләр чыгыш ясады.

Аерым алганда, «Ышаныч» иртә ярдәм күрсәтү үзәге вәкиле Анастасия Генералова аутизм турында хәзерге күзаллаулар турында сөйләде. «Аутизмнан интегүче балалар бер үк вакытта ике дөньяда яшиләр, – дип билгеләп үтте белгеч. – Беренче дөнья – аларның башларында, икенчесе – без барыбыз да яши торган дөнья, гомуми. Алар өчен үз дөньялары чынбарлыкка күпкә якынрак. Бу балаларны аңлый белү бик мөһим».

Алга таба Казан шәһәренең 8 нче балалар хастаханәсе психиатры Резеда Измайлова аутизмның медицина һәм социаль яклары турында сөйләде. Моннан тыш, кунакларны җырлар, шигырьләр һәм иҗади чыгышлар белән балалар үзләре дә сөендерде. Концерт программасы төгәлләнгәннән соң, сабыйлар мавыктыргыч мастер-классларда һәм фәнни шоуда катнашты.

■ **dum.rt**

Рамазанны каршы алабыз

Мөселманнар милади айларны белгән кебек, һиҗри айларны да белергә, аларның нәрсә аңлатканы, тарихлары белән кызыксынырга тиеш. Шул айларның берсе – Рамазан – мөселман тәкъвименең 9 нчы ае. Рамазан сүзе гарәп телендәге «рамада» сүзеннән һәм ул «кайнар», «эссе булу» дигәнне аңлата. Бу ай Гарәп ярымутравындагы бик эссе һава торышына туры килә торган була. Соңгы елларда безнең Татарстан җирлекләрендә дә ураза эссе һәм озын җәй айларына туры килеп барды. Әмма һиҗри календарь ай фазаларына нигезләнгәнгә күрә, ул ел дәвамында тотрыклы түгел, шунлыктан ел саен якынча 10 көнгә артка таба күчеп бара. Рамазан ае вакытында күктәге айга аеруча да игътибар ителә: күп кеше аның артканын һәм кимегәнен күзәтеп баралар.

Бүгенге көндә астрономия фәне бик алга китте, һәм шуңа күрә берничә ел алдан айның фазаларын төгәл әйтеп була башлады. Аллаһы Тәгалә Үзе дә Коръәни Кәримдә күктәге җисемнәрнең йөрешен системалы итеп тасвирлый, һәрберсе үзенә язылган юл белән бара дип әйтә. Рамазан аеның башланган көннәрен бу рәвешле билгеләүнең уңай яклары бик күп. Беренчедән, ул җиңеллек, икенчедән, шикле булган фаразардан коткарып кала һ.б.

Иң төп гыйбадәт – ураза

Безнең якларда исә Рамазанны «ураза ае» дип тә йөртәләр. Әлбәттә, моның да үз нигезе бар, чөнки Рамазан ае дигәч, нәкъ менә ураза күз алдына килә. Һәм бу айда кылына торган барлык гыйбадәтләрнең иң олуглары – биш вакыт намаз һәм ураза тоту. Әмма ураза тоту бу айда гына булмаганлыктан, Рамазанны аның белән генә чикләргә ярамый. Дөреслектә, бу бик фазыйләтле, бүләкләргә бай ай. Аллаһы Тәгалә бу айны калган айлардан аерып куйды. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам бу ай турында бик күп хәдисләр әйтеп калдырды.

Рамазанны яңа ел белән чагыштырып булыр иде. Октябрь-ноябрь айларында күп кеше: «Менә тиздән яңа ел җитә, әзерләнә башларга кирәк», – дип, яңа елга кадәр эшлисе эшләрне кылып бетерәләр, яңа елдан соңга планнар корып куялар. Шуның кебек Рамазанга да әзерлек бер ике ай элек башлана. Кеше табибларга барып, сәламәтлеген тикшертеп кайта, киңәшләр ала. Рамазан буена кылачак гамәлләрен барлый: Коръән уку, садака бирү, сәхәр һәм ифтар мәсьәләләре, тәравих намазы һ.б.

Ураза – ислам терәге

Нигез булмаса, өйнең диварлары, түбәсе тора алмас иде. Тамыры булмаса, агачлар шулай югары күтәрелә алмаслар иде. Исламның биш терәге бар дип әйтәбез. Терәк сүзе урынына кемдер багана, кемдер нигез сүзен дә куллана ала.

Аллаһы Тәгалә өчен иң якын гамәлләр нинди гамәлләр? Әлбәттә, фарыз, Ул Үзе тиеш дип билгеләгән гамәлләр. Шуңа күрә аларны үтәгән өчен әҗер-савабы да, үтәмәгән өчен гөнаһы да күбрәк. Аннан соң сөннәт, аннан мөстәхәб һәм башкалар.

Әбү Габдрахман Габдулла бине Гомәр бине Хаттаб радыяллаһу ганһе сөйләгән: «Мин Аллаһы Илчесенең: «Ислам биш терәккә нигезләнә: «Аллаһыдан башка илаһ юк, Мөхәммәд – Аның Илчесе» дип шәһадәт бирү, намаз уку, зәкят түләү, хаҗ кылу, Рамазанда ураза тоту», – дип әйткәнен ишеттем». Пәйгамбәребез әлеге хәдистә берничә фарыз гамәлне санап китә һәм шулар арасында Рамазан аенда ураза тоту да бар. Димәк, ураза – исламның терәге.

Тыелып торуда хикмәт бар

Ураза гарәп телендә «саум» – «тыелу» дигәнне аңлата. Һәрбер гамәл нәрсә дә булса эшләргә чакыра: намаз – хәрәкәтләр кылып укырга, садака бирер өчен кая да булса барырга кирәк, дәрес бирер өчен сөйләргә, аңлатырга кирәк. Ә саум дигән сүз, киресенчә, нәрсәне дә булса эшләмәскә, тыелып торырга куша. Рамазан аенда без ашау-эчүдән генә түгел, ә бөтен гөнаһлардан тыелып торырга тиешбез, югыйсә, уразабызга зур зыян китерергә мөмкинбез.

Аллаһының Илчесе галәйһиссәлам: «Мөэмин ураза тотып та, ачлыктан башка бернәрсәгә дә ирешмәскә мөмкин», – дип әйткән. Рамазан аенда безнең күзебез дә, колагыбыз да, телебез дә, йөрәгебез дә ураза тота. Ураза тотучының йөрәге тәкәбберлектән, көнчелектән, икейөзлелектән, ачудан пакь булыр.

Кунак килгәнче дип кеше җыештыру эшләре алып бара. Рамазан да моңа лаек. Кеше кирәкмәгән гадәтләреннән арына; намазны мәчеттә укуны тәртипкә сала; күңелен карайта торган сыйфатлардан пакьли һ.б. Аллаһының Расүле галәйһиссәлам: «Кем ялган сүзне калдырмаса һәм ялган белән эш итсә, аның ашамый, эчми торуы Аллаһыга кирәк түгел», – дип әйткән.

Рамазан безгә үзе булыша

Рамазан ае үзе белән бик күп бүләкләр алып килә. Ул изге гамәлләр өчен әҗер-савапларның арттырылып язылуы да, ай буе мәчеттә җәмәгать белән тәравихлар уку да, авыз ачу ашлары оештыру һәм аларга йөрү дә һ.б. Рамазан аеның тагын бер фазыйләтле бүләге – шәйтаннарның ай буе богауда булулары. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Рамазан аенда җәннәт капкалары ачык булыр, җәһәннәм капкалары бикле булыр, шәйтаннар чылбырда булыр», – дип әйткән. Бу исә вәсвәсә кыла торган шәйтаннарның булмавы, шуңа да бик күп итеп изге гамәлләр кылып калу мөмкинчелеге була дигәнне аңлата. Ә кем дә кем үзен изге гамәлләр кылырга ияләштерә, ул Рамазаннан соң да шулай ук дәвам итәчәк. Гомумән, кешенең уразалы булган көне, уразасыз көненнән аерылып торырга тиеш. Ә шәйтан-нарның богауда булуы моңа ярдәм итә. Шушы ук хәдистә җәннәт ишекләренең ачылуы һәм җәһәннәм ишекләренең ябылуы хакында әйтелә. Бу да Рамазан ае хөрмәтенә мөэмин-мөселманнарга Аллаһыдан бер бүләк.

Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә болай дип искәртә: «Кем дә кем (Рамазанда) Аллаһыга бер нәфел гамәл эшләп якынайса, калган айларда фарыз гамәлне кылган кебек, ә фарыз гамәл кылган кеше – 700 фарыз гамәл кылган кебек булыр». Шуңа да Рамазан аенда бик күп нәфел намазлар укып, садакалар биреп калырга өлгерергә кирәк, чөнки мондый мөмкинчелек елга бер генә килә.

■ ■ ■

Язларын агачлар үзләренең көчләрен кайтарган, яшелләнгән кебек, Рамазан аенда да кеше үзенең тәкъвалыгын, ихласлылыгын арттыра. Рамазан аенда кылырга мөмкин булган гыйбадәтләр саны артмый, без булган гыйбадәтләргә күбрәк басым гына ясый башлыйбыз: ярлы, мохтаҗ кешеләрне киендерү, ашату; түбәнчелеккә төшкәннәрне тартып чыгару, начарлыкка кул куймау һ.б. Шуңа да Рамазанны күңелдәге барлык яхшы сыйфатларның чәчәк ату чоры дип тә атыйлар.

Рамазан аеннан кала башка айларда тоткан уразалар бу ураза кебек саваплы булмас. Шуңа күрә бу айда көчебездән килгән кадәр изгелекләр кылып, намазлар укып калыйк. Аллаһы Тәгалә һәрберебезгә дә бу айны матур итеп каршы алып, күңелләребез, җаннарыбыз һәм тәннәребез үзгәргән халәттә озатып калырга насыйп әйләсә иде. Әәмин!

■ **Гәбделхәким Фәсхиев**

Ураза садакалары

Фитыр

Рамазан аенда фитыр садакасы һәм зәкят билгеләнә. Фитыр садакасы бирү һәр мөселманга да вәҗиб гамәлләрдән санала. Фитыр садакасын мөселман булмаганнардан һәм фәкыйрьләрдән тыш, бар кеше дә бирергә тиеш. Фитырны гаилә башлыгы барлык гаилә әгъзалары һәм аның тәрбиясендә булган кешеләр өчен үзенең кеременнән түли. Ир бала балигъ булуга, фитырны үзе өчен үз кеременнән түләргә омтылырга тиеш. Андый мөмкинлеге булмаган очракта, бу бурыч гаиләдәге башка ирәтлар өстенә төшә.

Авырлык белән яши торган фәкыйрь кешеләргә фитыр садакасын бирү вәҗиб түгел. Әгәр бирергә теләсәләр, үзләреннән дә фәкыйрьрәк кешеләргә бирергә тиеш булалар.

Фитыр садакасын Гайдел-фитыр көнендә таң атканнан соң Гает намазы укылганчы бирү саваплырак, чөнки бәйрәмне тояр өчен акчасы булмаган фәкыйрьләрне бәйрәм башланганчы шатландыру хәерлерәк. Фитыр садакасын Рамазан ае барышында ук биреп куярга да мөмкин. Зәкят һәм гошер кебек, фитыр садакасы да фәкыйрь, мохтаҗ кешеләргә генә бирелә.

Фитыр садакасының минималь күләме - 100 сум, зәкят чыгаручыларга - 600 сум.

Фидия

Рамазан аенда ураза тота алмаган кешеләр уразаларын башка айларда тота ала, уразаны бөтенләй тота алмаганнар исә фидия садакасы түләргә тиеш була. Фидия – ураза тотмаган көннәр өчен бирелә торган садака. Фидия акчалата түләнергә мөмкин.

Фидиянең күләме – 200 сум. Зәкят түләү өчен нисаб күләме 230 мең сумны тәшкил итә. Казага калып та, соңыннан үтәлмәгән уразалары булган кешегә, үзеннән калачак малыннан (тотылмаган уразалары өчен) фидия бирергә варисларына әйтү – вәҗиб. Әгәр шундый васыять әйткән кеше вафат булса, калган малының өчтән бер өлешен, каза кылынмый калган уразалары өчен дип, фидия итеп бирү варисларына вәҗиб була.

Ураза турында хәдисләр

Әбү Үмәмә радыяллаһу ганһе болай дигән: «Мин бер тапкыр Пәйгамбәребез галәйһиссәламгә килеп: «Әй Расүлуллаһ! Миңа җәннәткә кертәчәк берәр гамәл әмер ит», – дидем. Ул миңа: «Ураза тотуны дәвам ит, чөнки аңа тиң булырлык башка гамәл юк», – дип әйтте. Тагын бер тапкыр килеп, шул ук сорауны биргәндә: «Ураза тотуны дәвам ит, чөнки аңа тиң булырлык башка гамәл юк», – дип җавап кайтарды.

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе тапшырганча, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам болай дип әйткән: «Рамазан ае уразасын ихлас күңел белән ышанып һәм савабын бары тик Аллаһыдан гына өмет итеп тоткан һәркемнең кылган гөнаһлары ярлыканыр».

Әбү Һөрайрадан радыяллаһу ганһе риваять ителгәнчә, Расүлүллаһ галәйһиссәлам болай дип әйткән: «(Сәфәрдә булу) сәбәбе һәм хасталыгы булмаган кеше, Рамазанда бер генә көн ураза тотмаса, гомере буе ураза тоткан очракта да аны түләп бетерә алмас!»

Сөләйм угылларыннан берсенең болай дигәне риваять ителгән «Расүлүллаһ галәйһиссәлам: «Тәсбих (Сөбеханаллаһ)» үлчәүнең ярты гына, ә «Әлхәмдүлилләһ» аны тулыландыра. «Тәкбир (Аллаһу Әкбәр)» исә күк белән җир йөзе арасын тутыра. Ураза – сабырлыкның ярты, чисталык, пакьлек – иманның ярты», – дип әйтте».

Габдуллаһ бине Гамр радыяллаһу ганһе Расүлүллаһ галәйһиссәламнең болай дип әйткәнен тапшырган: «Ураза белән Коръән Кыямәт көнендә колга шәфәгать итәчәкләр. Ураза: «Әй Раббым! Мин аны көндезләрен ашауэчүдән һәм җенси теләкләреннән тыйдым. Шуңа күрә мине аның өчен шәфәгатьче кыл», – дип әйтәчәк. Коръән дә: «Мин аны төннәрен йоклатмадым. Мине дә аның өчен шәфәгатьче кыл», – дип әйтәчәк. Шулай итеп, икесе дә (әлеге колга) шәфәгать итәчәкләр».

Җәбир радыяллаһу ганһе тапшырган бер хәдистә Пәйгамбәребез галәйһиссәлам болай дигән: «Һичшиксез, ураза колның үзе өчен җәһәннәмнән саклый торган калкан. (Аллаһы Тәгалә): «Ул (ураза) Минем өчен һәм аның савабын да Мин бирәчәкмен», – дип әмер итте».

Габдуллаһ бине Әбү Әүфа радыяллаһу ганһе риваять иткән бер хәдистә Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Ураза тоткан кешенең йокысы – гыйбадәт, эндәшмәве – тәсбих, гамәле даими, догасы кабул ителгән, ә гөнаһы гафу ителгән булыр», – дип әйткән.

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе тапшырган бер хәдистә Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Ураза – сабырлыкның ярты. Һәрнәрсәнең зәкяте бар. Тәннең зәкяте – ураза», – дигән.

«Һичшиксез, җәннәтләр дүрт кешегә гашыйк. Болар: Рамазан аенда ураза тоткан, Коръән укыган, телләрен (ялган һәм шуңа охшаш яманлыклардан) саклаган, күршеләрен ашаткан кешеләр.

«Хакыйкатьтә, Аллаһы Тәгалә ифтар вакытында мөселман колының аяклары белән йөргән, куллары белән тоткан, күзләре белән күргән, колаклары белән тыңлаган, теле белән сөйләгән һәм йөрәге белән уйланган (барлык гөнаһларны да) гафу итәр».

Әбү Мәлик Әл-Әшгари риваять иткән бер хәдистә Пәйгамбәребез галәйһиссәлам болай дигән: «Чынлыкта, җәннәттә шундый бер йорт бар: эченнән – тышы, тышыннан эче күренә. Аллаһы Тәгалә аны йомшак сөйләшкән, кешеләрне ризыкландырган, даими ураза тоткан һәм башка кешеләр йоклаганда төнлә гыйбадәт кылганнар өчен әзерләгән».

Уразага бәйле кайбер мәсьәләләр

Беренче тәравих намазы 5 май көнне ястү намазыннан соң укылачак һәм 20 рәкәгатьтән торачак. 4 июнь көнендә гает намазы укылачак.

Рамазан ае кергәнче үк ураза тотарга теләгән кеше үзенең ниятен дөресләп куярга тиеш. Ул фәкать Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен, Аның әмерләрен үтим дип ният кыла.

Шулай итеп, безнең ниятебез ураза тотуга юнәлгән. Иртәләрен ураза тотар алдыннан түбәндәге сүзләрне (гарәпчә) укып, тел белән ният кылу мөстәхәб санала:

نَوَيْتُ أَنْ أَصُومَ شَهْرِ رَمَضَانَ مِنَ الْفَجْرِ إِلَى الْمَغْرِبِ خَالِصًا لِلَّهِ تَعَالَى

Нәвәйтү ән әсуумә саумә шәһри рамәдаанә минәл-фәҗри иләлмәгъриби хаалисан лилләәһи тәгааләә.

Мәгънәсе: «Аллаһы Тәгалә өчен, ихласлык белән таң вакытыннан башлап, кояш батканчыга кадәр Рамазан уразасын тотарга ният кылдым».

Кояш баткач ниндидер ризык, тоз яки су белән ифтар кылу, ягъни авыз ачу – сөннәт. Хөрмә кебек татлы җимешләр белән ифтар кылу – мөстәхәб.

Ифтардан соң (авыз ачканнан соң) түбәндәге дога укыла:

اَللَّهُمَّ لَكَ صُمْتُ وَبِكَ أَمَنْتُ وَعَلَيْكَ تَوَكَّلْتُ وَعَلَى رِزْقِكَ أَفْطَرْتُ. فَاغْفِرْ لِي يَا غَفَّارُ مَا قَدَّمْتُ وَمَا أَخَّرْتُ

Аллаһүммә ләкә сумтү вә бикә әмәнтү вә галәйкә тәвәккәлтү вә галәә ризкыйкә әфтартү фәгъфирлии йәә гаффәәру мә каддәмтү вә мәә әххартү.

Мәгънәсе: «Аллаһым, шушы уразамны Синең өчен тоттым, Сиңа гына иман китердем һәм Сиңа тәвәккәл иттем. Синең ризыгың белән авыз ачам. Әй гөнаһларны гафу итүче Аллаһым, минем әүвәлге гөнаһларымны да, соңгы гөнаһларымны да ярлыка».

Рамазанда да гөнаһларны калдыра алмасак...

Әлхәмдүлилләһи раббил гааләмиин, әссәләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә асхәәбиһи әҗмәгыйн, әммә багъде: барча мактауларыбыз галәмнәрне юктан бар кылган Аллаһы Тәгаләгә булса иде. Һәм дә салават-шәрифләребез Аның хәбибе Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә булса иде.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, әссәламү галәйкүм вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтуһ.

Әлхәмдүлилләһи раббил гааләмиин, без даими рәвештә Аллаһы Тәгаләгә хәмед-саналәребезне әйтәбез. Әлхәмдү лилләһи Раббил гааләмиин, аның сөекле илчесе Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават-шәрифләребезне җиткерәбез. Аеруча шушы айда – Рамазан-шәрифтә гыйбадәтләребезне тагын да арттырабыз. Намазларыбызны мөмкин кадәр камилрәк укырга тырышабыз. Вакытында уку турында сүз дә юк – монысы намазның шарты. Фарыз намазларын мәчеттә җәмәгать белән уку җаен табарга тырышабыз. Уразаларыбызны төп-төгәл итеп тоту өчен көч куябыз. Сәхәргә торабыз. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сөннәтенә ияреп, аның: «Сәхәрдә – бәрәкәт», – дигән сүзләренә итагать итеп, шул вакытта Аллаһы Тәгалә биргән тәгамнәр белән ризыкланабыз. Ифтарларга йөрибез. Вәгазьләнәбез. Машинада барганда җырлар түгел, ә Коръән тыңлыйбыз. Егерме рәкәгать тәравихларда да торабыз. Нәфел гыйбадәтләрен өстәргә тырышабыз.

Әмма, Рамазан үттеме – барысы да онытыла. Шушы бәрәкәтле көннәр ничек килеп җиткән булса, шулай ук үтеп тә китәчәк. Бер ияләшкән гадәт белән биш вакыт намазга мәчеткә йөрербез. Шәүвәлдә ураза да тотарбыз. Ләкин гаеттән ерагайган саен Рамазан дәресләрен онытабыз... Мәчеткә җомгага гына киләбез. Нәфелләрне калдырабыз. Изгелектән ерагаябыз.

Нигә? Чөнки бәрәкәтле Рамазан аенда да, күпме генә гыйбадәт кылсак та, гөнаһтан арына алмыйбыз. «Ничек инде, хәзрәт?! Ураза тотам бит. Намаз укыйм бит. Гөнаһ кылырга вакытым юк бит», – диярсез. Чынлыкта, без гөнаһлы тормышка шулкадәр ияләшкән ки, аны сизмибез дә. Рамазан ае уразасы, биш вакыт намаз – болар фарыз гыйбадәт, без аларны үтәргә тиеш. Кылмыйбыз икән – гөнаһлы булабыз. Бу безнең изге бурычыбыз, аның белән масаясы түгел. Масайсаң, бу – рия: гамәл-гыйбадәтеңне Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен түгел, башкалар күрсен, мактасын, синнән көнләшсен өчен кылынган эш.

Рамазан ае – айларның солтаны. Шушы айда Аллаһы Тәгалә Коръәнне индерә башлады. Шулай ук бу айда Кадер кичәсе бар.

«Кадер киче савабы мең айдан да хәерлерәк, мең ай кылган гыйбадәттән артыграктыр».

«Кадер / Кадер Киче», 97:3

Бу айда шәйтаннар богауда булалар, без үз нәфесебез белән генә калабыз. Нәрсә эшлибез, нәрсә кылабыз, нинди сүз сөйлибез – барысын да үзебез кылабыз. Берәүне дә гаепли алмыйбыз.

Шуңа да бу айда гөнаһлардан тыелу, күңелебездә кыек эшләргә карата тиешле мөнәсәбәт тәрбияләү мөһим. Чынлыкта, адәм баласының нәфесе гөнаһка ияләшә. Башта кечкенә генә ялгышлык та аның күңелен борчый. Аннары калебтәге шул тап зурайганнан зурая бара. Һәм кеше олы гөнаһларга да кереп китүен сизми кала. Раббыбыз Үзе сакласын.

Рамазан аенда гыйбадәтләребезне арттырып, фарыз гамәлләребезне кылу дәрәҗәсен күтәреп, без нәфесебезне тагын да тәрбиялибез. Еш кына: «Хәзрәт, бер танышым бар, Рамазанда ураза тота, үзе намаз да укымый, яулык та япмый», – дип сорыйлар. «Үзең ураза тотасыңмы?» – дип сорасаң: «Юк», – дип җавап бирә. Намаз да укымый. Әйе, намаз укымау – гөнаһ. Ураза тотмау да гөнаһ. Ләкин Аллаһы Тәгалә кемнең дә булса күңеленә ураза тоту теләген салды икән – шул орлыкны үтермик. Үзебездән башлыйк. Бәлки шул Рамазанда ураза тотканнан соң кеше намазга да басар. Ифтарларга йөреп, вәгазьләнер. Ялгыш юлда булуын аңлар, хаталар төзәтү өчен тырыша башлар.

Әлхәмдүлилләһ, Рамазан ае җитү белән мәчетләребез тула. Бүген әле намаз укымаган кардәшләребез дә, кимендә, гөнаһлардан сакланырга тырыша. Кайбер авыллардагы, төбәкләрдәге кибетләрдә, әйтик, харам сату тыела. Кеше тәмәке тарта икән – тартмаска тырыша, аракы эчә икән – шушы айда тыелып тора. Ин шә Аллаһ, аларның шул рәвешле нәфесләрен җиңәргә тырышуы җавапсыз булмас. Башта харамнан читләшер, аннан гыйбадәтләрен кыла башлар. Аллаһы Тәгаләнең сөекле бәндәләреннән булыр, ин шә Аллаһ. «Син әле намаз да укымыйсың, ничек ураза тотасың», – дип әйтәбез икән – шәйтанга ярдәм итәбез, димәк, аның эшен эшлибез. Адәм баласын гыйбадәттән читләштерәбез. «Синең Рамазан аенда гына гөнаһтан тыелып торуыңнан ни файда?» – дип күңелләрен төшермик. Һәм икейөзлелектә гаепләмик. Киресенчә, булышыйк: ифтарга чакырыйк. Берәрсе гөнаһлардан тыелырга ихтыяр көче тапмый икән – күркәм нәсыйхәт кылыйк.

> Кадер киче савабы мең айдан да хәерлерәк, мең ай кылган гыйбадәттән артыграктыр».
>
> *«Кадер / Кадер Киче», 97:3*

Ә моның өчен үзебезгә гөнаһлардан арыну кирәк. Хаклыкка кайтыр өчен Рамазаннан да хәерлерәк чор юк. Әгәр дә Рамазан-шәрифтә гөнаһлы гамәлләрдән, яман фикерләрдән тыела алмыйбыз икән – башка вакытта бу бик авыр биреләчәк. Рамазан – ул мәдрәсә. Рамазан – ул тәрбия. Һәм шул дәресләрдән мөмкин кадәр күбрәк файда алу өчен калебебезне гөнаһлардан чистарту кирәк. Кем Рамазанда ураза тотып та, ач кылу дәрәҗәсен генә алса, ни үкенеч аңа. Ни үкенеч шул кешегә, кем төннәр буе тәравихлар укып та, төне буе уяу торган кебек кенә саналса. Һәм ни үкенеч шул кешегә, кем Рамазан аен гамәл-гыйбадәттә үткәреп тә, гөнаһлары ярлыкланмаса.

Мөхтәрәм дин кардәшләрем! «Гөнаһлардан арыныйк дигән сүз миңа кагылмый, әнә, уразасыз, намазсыз кеше кайгырсын», – дип уйламыйк. Уразалы килеш тә гайбәттән арына алмыйбыз. Раббыбыз ураза тотучыларны җәннәткә Әр-Раян дип аталган капкадан кертер, ин шә Аллаһ. Һәм бу капкадан ураза тотучылардан гайре башка беркем кермәс. Шул дәрәҗәне күршебезне, туганыбызны «чәйнәүгә» алыштырабызмы? Рамазан аенда, аеруча Кадер кичәсендә кылынган изгелегебез өчен савап мең тапкырга кадәр җитәргә мөмкин. Раббыбызның рәхмәте киң, шул рәхмәтне бозык сүзгә алыштырабызмы? Ураза килеш тә талашудан тыелмыйбыз. Рамазанда да күз зинасыннан оялмыйбыз. Тапкан малыбыз хәләлме? Әллә ифтарларда яман юл белән килгән ризыклар белән авыз ачабызмы? Рамазан – ул уйлану ае. Өстеңнән хисап тотканчы, үз-үзеңә хисап тоту ае.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләре Рамазаннан соң ярты ел дәвамында әле Аллаһы Тәгаләдән уразаларын кабул итүне сорыйлар иде. Ялварып дога кылдылар. Без исә ярым-йорты уразабыз кабул булуына шиксез ышанабыз. Ураза кабул булуның бер билгесе булып безнең Рамазаннан соң да гамәл-гыйбадәтләребезне киметмәвебез; Рамазанда гөнаһлардан сакланып, шул яшәү рәвешен дәвам итүебез тора.

Зәгыйфьлегебезне җиңик. Көчле мөселман булыйк. Үз нәфесебезгә хуҗа булыйк. Рамазан аенда күңелебезне пакьлик. Ураза гаетенә анадан туган сабый сыман гөнаһсыз килик. Раббыбыз һәрберебезгә шундый мөмкинлек биргән – шушы шәрәфле айның бәрәкәтен күңелләребезгә сеңдерик. Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтуһ.

■ **Рөстәм хәзрәт Хәйруллин,**
Казанның «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы

Сәхәрсез ураза дөресме?

Мин сәхәр ашамыйча гына ураза тотам. Дөрес эшлимме?

Ураза тотарга ниятләгән кеше сәхәр ашамыйча ураза тота икән, аның уразасы дөрес була. Әмма сәхәргә тору – уразаның әдәбе булып тора. Пәйгамбәребез: «Сәхәр ашагыз, дөреслектә, сәхәрдә бәрәкәт бар», – дип әйткән.

Уразада көнне йоклап үткәреп буламы?

Ураза җәй көннәренә туры килгәндә көн бик озын була, вакыт акрын уза. Вакытны тизрәк уздыру өчен көндез озаграк йокларга тырышам. Минем уразам дөресме?

Уразагыз дөрес, чөнки йокы уразаны бозмый. Ләкин шуны истә тотарга кирәк: ураза безгә күп йоклау һәм ифтарда күп ашау өчен фарыз ителмәде, ә бәлки гыйлем эстәү, изге гамәлләрне күбрәк кылу, Аллаһы Тәгаләгә якынаю өчен фарыз кылынды.

Уразаны телевизор карау бозамы?

Телевизор карау уразаны бозмый. Әмма әхлаксызлык, сугыш, җенси теләкне уята торган тапшырулардан ерак булу яхшырак. Алар мөселманнар өчен тыелган. Болар уразага зәгыйфьлек китерә. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Ураза ул – үзеңне ризыктан гына түгел, ураза ул – үзеңне начар гадәтләрдән, начар күренешләрдән дә саклау», – дигән сүз.

Гайбәт һәм ураза

Мин үзем ураза тотмыйм. Күрше: «Мин уразада», – ди. Үзе гайбәт сөйләп йөри. Аның уразасы кабул буламы?

Аллаһы Тәгаләнең «Гаепләүче» дигән исем-сыйфаты бар. Бу әйберне сөйләп сез үзегез гайбәт сөйләүче булдыгыз, чөнки беренчедән, үзегез ураза тотмыйсыз, икенчедән, ураза тотучы мөселман кешесе турында гайбәт таратасыз. Әлбәттә, гайбәт, ялган сөйләүне вә бозык сүзләр белән эш кылуны куймаган кешенең уразасы Аллаһы Тәгалә каршында кабул булмаска мөмкин, ягъни Аллаһы Тәгалә ихласлык белән кылынган гамәлне генә кабул итә. Ихлассыз эшләнгән, ялган вә рия катышкан гамәлне һич кабул кылмыйдыр. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Ий мөэминнәр! Аллаһы Тәгалә гамәлләрегезнең ихласлысын, Үзе өчен кылынган гамәлне генә кабул кыла, башкаларын кабул кылмый», – дигән.

Янә икенче бер хәдисендә: «Аллаһы Тәгалә сезнең кыяфәтегезгә дә, малыгызга да карамас, бәлки, күңелләрегезгә вә кылган гамәлләрегезгә карар», – дип әйтә.

Кемнең күңеле саф вә сәламәт булса, Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен кылган гамәле ихластан булса, ул кешенең гамәлләре Аллаһы Тәгалә каршында хөрмәтлелек кылган изге гамәлләр вә тәкъвалык илә казанылыр.

Коръән Кәримнең «Әл-Хүҗүрат» сүрәсе, 13 аятьтә әйтелә: **«Аллаһы Тәгалә каршында Аннан куркып гөнаһлардан саклангангыгыздыр»**. Бу аяти кәримәдә әйтелгәннән күрәбез ки, кемнең тәкъвалыгы күбрәк булса, Аллаһы Тәгалә каршында ул хөрмәтлерәктер. Күңелдә тәкъвалык булмыйча, тышкы сурәт тәкъвалыгы гына булса, тән әгъзалары да харам эшләрдән тыела алмаслар. Бу вакытта Аллаһы Тәгалә мондый кешеләргә карата «Әл-Мүнтәгыйм», ягъни «Гаепләүче» була.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам әйтә: «Хәбәрдар булыгыз, хакыйкатьтә, тәндә бер кисәк ит бардыр. Әгәр ул кисәк ит төзек булса, бөтен тән төзек булыр. Ул бер кисәк ит – йөрәктер», – дигән.

Намаз укымауның уразага тәэсире

Намаз укымаган кешенең уразасы кабул буламы? Намаз бит динебезнең асылы.

Дөрестән дә, намаз уку ул – динебезнең асыл нигезен тәшкил итә торган гыйбадәт, әмма шәригатебездә һәрбер гыйбадәт аерым-аерым карала. Намаз турында: «Әгәр намазы булмаса, башка гыйбадәтләре дә кабул булмый», – дигән хәдис бар. Ләкин мондый хәдисләр, адәм балалары намазга җиңел карамасыннар өчен, намазның никадәр өстен гыйбадәт икәнлеген раслый торган мәгънәдә килә. Фикһ галимнәре: «Кеше намаз укымый икән, аның тоткан уразасы кабул булмый», – дигән фәтвәгә дәлил юк. Димәк, намаз аерым бер төр гыйбадәт, ураза тоту – аерым бер төр гыйбадәт, хаҗ кылу да, зәкят бирү дә – шулай ук», – дип әйттеләр. «Намаз укымасаң, ураза тотма, ул кабул булмый яисә син буш гамәл кыласың», – дип әйткән кеше үзе гөнаһлы була.

■ **Җәгъфәр хәзрәт Мөбарәк «Һәр мөселман белергә тиешле нәрсәләр» китабыннан**

Рамазан аенда намаз уку рәвешен искә төшереп үтегез әле

Сорау: Рамазан аенда фарыз һәм билгеле сөннәтләрдән башка артык намаз бармы?

Җавап: Пәйгамбәр галәйһиссәлам: «Әгәр берәү савап өмет итеп, Рамазан аенда ураза тотса, элек кылган гөнаһлары гафу ителер, шулай ук берәү савап өмет итеп, Рамазан аенда намаз укыса, элек кылган гөнаһлары гафу ителер».

***

Сорау: Рамазан аеның төннәрендә намаз ничек укыла?

Җавап: Имам ястүдән соң җәмәгать белән егерме рәкәгать намаз укый, һәр ике яки дүрт рәкәгатьтән соң сәлам бирелә һәм тукталып ял ителә. Тәравих намазында һәр дүрт рәкәгатьтән соң ял итү өчен бераз утырганнан соң намаз янә дәвам ителә.

***

Сорау: Биш тәравихнең мәгънәсе ничек?

Җавап: «Һәр дүрт рәкәгать намаз – бер тәравих» дип атала. Шуның өчен «Тәравих намазы» дип йөртелә.

***

Сорау: Бу намаз хатын-кызлар өчен дә сөннәтме?

Җавап: Әйе, рамазан аенда ястүдән соң егерме рәкәгать намаз уку хатын-кызлар һәм ирләр өчен – сөннәти-мүәккадә. Тәравих намазын ирләр мәчеттә җәмәгать белән укыйлар, хатын-кызлар өчен өйдә уку яхшырак.

***

Сорау: Рамазан аенда витр намазы җәмәгать белән укыламы?

Җавап: Әйе, имам тәравихне укытып бетергәч, витрны җәмәгать белән өч рәкәгатьтә дә кыйраәтне кычкырып укый, имам һәм иярүчеләр «Кунут» догасын эчтән генә укыйлар.

***

Сорау: Рамазан аеннан башка вакытта витрны җәмәгать белән укыйлармы?

Җавап: Рамазаннан башка вакытта витр намазы җәмәгать белән укылмый.

■ **Мөхәммәд Гашыйк Иләһи Әл-Бәрни «Әт-тәсһил әз-зарури ли мәсәил Әл-Кудури» китабыннан**

«Татар телен саклау һәм популярлаштыру – мәдрәсәләр һәм ислам югары уку йортлары өстендә»

16 апрель көнне, ягъни Шәгъбан аеның 11 нче көнендә, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте резиденциясендә мөселман дини мәгариф оешмалары – Татарстан мәдрәсәләре директорлары киңәшмәсе узды. Әлеге утырыш эшендә Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин һәм мөфтинең мәгариф буенча урынбасары, Россия ислам институты ректоры Рәфикъ хәзрәт Мөхәммәтшин катнашты. Киңәшмә барышында һөнәри мөселман мәгарифенә караган уку-укыту стандартларын тормышка ашыру мәсьәләләре каралды һәм республика мәдрәсәләрендә узган методик көннәр буенча нәтиҗәләр ясалды.

Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте карамагында үз эшләрен алып бара торган мәгариф учреждениеләре җитәкчеләренә яшь буынны укыту һәм тәрбияләү юлында кулга-кул тотынып, намуслы хезмәт кылганнары һәм Татарстан мөселман мәгариф системасы үсешенә керткән өлешләре өчен Татарстан мөфтие исеменнән рәхмәт сүзләрен җиткерде. Ул дини уку йортлары җитәкчеләренә мөрәҗәгать итеп, мәдрәсәләрнең татар телен һәм рухи кыймәтләрне саклап калуда зур өлеш кертүен ассызыклап узды: «Башлангыч мәдрәсәләрдән алып, югары ислам уку йортларына кадәр телебезне популярлаштыруны кайгырту юнәлешен бергәләп дәвам иттерергә кирәк. Берничә елдан халкыбызның үз ирке белән рәсми рәвештә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын билгеләп үтәчәкбез. Шәкертләрне рухи мирасыбызга, милли мәдәниятебезгә мәхәббәт тәрбияләп, рухи мирасыбызны яхшы белүчеләр итеп тәрбияләү тиешле». Рөстәм хәзрәт, тәкъдим буларак, «Хозур» нәшрият йорты тормышка ашырган «Дәрүл кутуб» сайтында иске татар язуында бирелгән һәр китапны шәкертләрнең кереп укуларын һәм иске имляны камил дәрәҗәдә белүләрен таләп итеп куйды.

Җыелышның көн тәртибенә күчеп, мәдрәсә җитәкчеләрен Рәфикъ хәзрәт Мөхәммәтшин сәламләде. Ул мөселман мәгариф оешмалары, үзәкләр, мәктәпләр үсеше концепциясе хакында саллы чыгыш ясады.

Ул шулай ук, үз чиратында, һөнәри мөселман оешмаларында мәгариф стандартларын тормышка ашыру буенча тәкъдимнәрен җиткерде, дини мәгариф оешмаларына җәмәгатьчелек аккредитациясе үткәрү турында сөйләде.

Нәзарәтнең фән һәм мәгариф бүлеге мөдире Айдар Карибуллин Татарстан мәдрәсәләрендә, мөселман мәктәпләрендә һәм үзәкләрендә үткәрелгән Методик көннәргә нәтиҗәләр ясады. Ул ачык дәресләр карап, үз профиле буенча белем бирүче мөгаллимнәрнең актив катнашулары өчен рәхмәт сүзләрен белдерде. Ютазы районы Урыссу бистәсенең «Фәнис» мәдрәсәсендә үткәрелгән «Дини гыйбадәт кылу нигезләре» предметы буенча узган дәрес үрнәкләрен мисал итеп китереп, бу фәнне үзләштерүдә матди-техник базаны яхшырту ниятеннән нәзарәт тарафыннан ярдәм күрсәтеләчәге хакында белдерде. Аерым алганда, һәр мәдрәсәдә сыйныфны махсус рәвештә җиһазлау, кирәк әсбаплар, принтер, оргтехника, фото һәм видеоаппаратура алу күздә тотыла. Иң яхшы дәрес үрнәкләре мөфтият һәм мәдрәсә карамагында булган сайтларга эленәчәк.

Җыелыш барышында киләсе елда уку-укыту барышын камилләштерү, шулай ук 2018-2019 уку елында мәдрәсәләрне тәмамлаучылар саныннан кадрлар резервын туплау һәм шәкертләрне эшкә урнаштыру буенча да тәкъдимнәр яңгырады. Шулай ук һәрбер җитәкче ел дәвамында эшләнгән эшләргә һәм үткәрелгән чараларга нәтиҗәләр ясады, киләсе уку елына абитуриентларны актив җәлеп итү буенча тәкъдимнәрен җиткерде.

Шунысы игътибарга лаек, Татарстанда хәзерге вакытта 9 мәдрәсә, Россия ислам институты һәм Болгар ислам академиясе бар, аларда 240 мөгаллим хезмәт кыла һәм 3852 шәкерт белем ала. Татарстан территориясендә урнашкан 690 мәчет каршындагы Ислам нигезләре һәм дини тәрбия буенча курсларда 12250 шәкерт укый, 1450 кеше остазлык итә. 2018-2019 уку елыннан Әлмәт шәһәрендә татар телендә белем бирә торган «Нур» башлангыч мәктәбе һәм Балтач районы Бөрбаш авылында малайлар пансионаты эшли башлады. Барлык дини уку йортлары үз эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан бирелгән лицензия нигезендә алып бара. 2017 елда Болгар ислам академиясе ачылышы белән Татарстан Республикасында дини мәгариф системасы тулысынча формалашып җитте, ул дүрт баскычтан тора: мәчет каршындагы курслар – мәдрәсә – институт – академия.

■ **dum.rt**

Татарстан мөфтияте һәм Бөтендөнья ислам лигасы арасында хезмәттәшлек турында килешү имзаланды

5 апрель көнне Казан Кремлендә Бөтендөнья ислам лигасы Генераль сәркатибе Мөхәммәд бине Гәбделкәрим Әл-Иса җитәкчелегендәге Согуд Гарәбстаны Корольлеге делегациясе белән очрашу узды. Очрашуны Губернатор сараенда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов үткәрде. Анда Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин да катнашты.

Исегезгә төшерәбез: Бөтендөнья ислам лигасы Генераль сәркатибе Мөхәммәд бине Гәбделкәрим Әл-Иса җитәкчелегендәге Согуд Гарәбстаны Корольлеге делегациясе 4-7 апрель көннәрендә Татарстанга эшлекле сәфәрдә. 5 нче апрель көнне иртән делегация вәкилләре ТР мөселманнары Дания нәзарәтендә дә булды. Кунакларны Камил хәзрәт Сәмигуллин каршы алды. Моннан тыш, делегация Казан (Идел буе) федераль университетында, Россия ислам университетында булырга, Болгар ислам академиясе эшчәнлеге белән таныштты.

Казан Кремлендә узган әңгәмә барышында Россиянең ислам дөньясы белән багланышлары мәсьәләләре буенча фикер алышу узды. Татарстан Президенты дөньяда гомумкешелек һәм рухи кыйммәтләрне ныгыту эшендә хезмәттәшлекнең уңышлы һәм нәтиҗәле булачагына өмет белдерде. Очрашу азагында Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Дания нәзарәте һәм Бөтендөнья ислам лигасы арасында хезмәттәшлек турында килешү имзаланды. Документка мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм Мөхәммәд бине Гәбделкәрим Әл-Иса кул куйды.

Тулаем алганда, ТР мөселманнары Дания нәзарәтенең халыкара эшчәнлеге Татарстан Республикасының һәм мөфтиятнең абруен күтәрү, шулай ук ислам үсеше өлкәсендә халыкара аренадагы урынны ныгыту, дөньякүләм мөселман киңлеге һәм мәгариф берләшмәләре белән ике яклы багланышта торуны арттыру максатыннан тормышка ашырыла. Әлеге өлкәдә Татарстан Республикасы мөселманнары Дания нәзарәте чит ил оешмалары белән элемтәләрне киңәйтү, яңа партнерларны нәтиҗәле юл белән эзләү һәм яңаларын җәлеп итү, мәгариф программасы, Коръәнне өйрәнү, социаль хезмәт күрсәтү спектрын арттыру нәтиҗәсендә сизелерлек уңышларга ирешті. Әлеге бурычларны тормышка ашыру өчен 2018 елда Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин 9 тапкыр эш сәфәре белән чит илләргә чыкты, моннан тыш Татарстан Республикасы мөселманнары Дания нәзарәте резиденциясе дә шәһәрнең мактаулы кунаклары белән очрашу урынына әверелде. Нәзарәттә мөфти чит ил вәкилләре – мөселман галимнәре һәм фән эшлеклеләре, дәүләт һәм иҗтимагый оешма җитәкчеләре, илчеләр, мөфтиләр, журналистлар һ.б. белән рәсми очрашулар үткәрде. Чит илләрдән килгән кунакларга Камил хәзрәт татарларда ислам дине тарихы һәм үсеше, мөфтиятнең күпкырлы эшчәнлеге турында сөйләде, шулай ук алар белән ислам диненең традицион кыйммәтләрен ныгыту өлкәсендәге тәҗрибәсе белән бүлешті. Кунакларда татар рухи мирасының байлыгы хакындагы мәгълүмат, татар дини мирасының ислам дөньясындагы урыны, Россиядә ислам үсеше, Татарстанда ислам мәгарифе өлкәсендәге казанышлар, экстримизмга көрәш һәм дәгъват эшчәнлеге шулай ук зур кызыксыну уятты. Татарстан Республикасы мөселманнары Дания нәзарәтенең халыкара мөнәсәбәтләр үсеше өлкәсендә иң зур казанышы булып, БМОның Икътисад һәм социаль советы каршында консультатив статус бирелүе тора.

■ **dum.rt**

ТӘРАВИХ НАМАЗЫ

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Аллаһы Тәгалә бу айда (Рамазанда) ураза тотуны фарыз, ә төннәрен намаз белән үткәрүне сөннәт итеп кылды», – дип әйткән. Галимнәребез «төннәрен намаз белән үткәрү» дигәнне тәравих намазы дип әйтәләр. Чыннан да, Рамазан аенда уразадан кала икенче зур гамәл – ул тәравих намазы. Тәравих намазы Рамазан аенда укыла. Ул 20 рәкәгатьтән тора. Тәравих намазын мәчеттә уку – сөннәт, аны үтәгән өчен зур савап вәгъдә ителгән. Әмма әлеге намазны өйдә берүзең укысаң да ярый.

Тәравих намазын бары тик ястү намазыннан соң гына укырга була. Рамазан аенда витр намазы тәравих намазыннан соң укыла. 20 рәкәгатьле тәравих намазында сәламне һәр ике рәкәгатьтән соң яки һәр дүрт рәкәгатьтән соң бирергә була. Тәравих сүзе «ял итеп алу» дигән сүздән килеп чыккан. 20 рәкәгатьле тәравих намазын 5кә бүлеп ял итүебез дә шуны аңлата. Шушы ял итү вакытында түбәндәге зикерне әйтү динебездә күркәм гамәлләрдән булып санала. Гадәттә, аны мәкам белән, матур итеп көйләп укыйлар.

سُبْحَانَ ذِي الْمُلْكِ وَالْمَلَكُوتِ سُبْحَانَ ذِي العِزَّةِ وَالعَظَمَةِ وَالْقُدْرَةِ وَالْكِبْرِيَاءِ وَالجَبَرُوتِ سُبْحَانَ الْمَلِكِ الْحَيِّ الَّذِي لَا يَمُوتُ سُبُّوحٌ قُدُّوسٌ رَبُّنَا وَ رَبُّ الْمَلَائِكَةِ وَ الرُّوحِ لَا إِلَهَ إِلَّا الله نَسْتَغْفِرُالله نَسْأَلُكَ الْجَنَّةَ وَ نَعُوذُبِكَ مِنَ النَّارِ

«Сүбхәәнә ҙил-мүлки вәл-мәләкүүт. Сүбхәәнә ҙил-гыйззәти вәл-газамәти вәл-кудрати вәл-кибрияя-и вәл-җәбәруут. Сүбхәәнәл-мәликил-хәййил-ләҙии лләә йәмүүт. Сүббүүхүн куддүүсун раббүнә вә раббүл-мәләәикәти вәрруух. Лләә иләәһә илләллааһу нәстәгъфируллаah. Нәс'әлүкәл җәннәтә вә нәгууҙү бикә минән нәәр».

Мәгънәсе: **Яшерен вә ачык булган һәрнәрсәнең Иясе чиста Пакь. Көч-Куәт, Бөеклек, Күркәмлелек Иясе Пакь. Ул Мәңге исән һәм беркайчан да үлмәс. Камиллек Иясе, Кимчелексез, Ул – безнең Раббыбыз, фәрештәләрнең һәм җәннарның Раббысы. Аллаһыдан башка илаһ юк һәм без Аннан гөнаһларыбызның ярлыкавын сорыйбыз. Йә, Раббым, без Синнән җәннәт сорыйбыз һәм ут газабыннан сыенабыз.**

Соңгы ун көндә түбәндәге зикер әйтелә:

سُبْحَانَ الْمَلِكِ الْحَنَّانِ الْمَنَّانِ، سُبْحَانَ الْمَلِكِ الدَّيَّانِ، اَلْمَعْرُوفِ بِالْغُفْرَانِ وَالْمَوْصُوفِ بِالْإِحْسَانِ. اَلْوَدَاعُ اَلْوَدَاعُ اَلْفِرَاقُ اَلْفِرَاقُ يَا شَهْرَ رَمَضَانِ. اَللَّهُمَّ يَا قَدِيمُ يَا حَكِيمُ يَا عَلِيمُ اغْفِرْلَنَا يَا كَرِيمُ يَا رَحِيمُ يَا حَلِيمُ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ.

Сүбхәәнәл мәликиль хәннәәнил мәннәән. Сүбхәәнәл мәликид дәййәән. Әлмәгьрууфү бильгуфраан. Әлмәүсууфү биль ихсәән. Әлвәдәәгь. Әлвәдәәгь. Әльфираак. Әльфираак, йәә шәһру рамәдаан. Аллаһуммә йәә кадиим, йәә хәкиим, йәә галиим игъфир ләнәә йәә кәриим йәә рахиим йәә хәлиим йәә әрхәмәрраахимиин.

Мәгънәсе: **Юмарт һәм Рәхимле булган Хаким Пакьтер. Ярлыкаучы буларак билгеле, игелеге белән аерылып торган Хөкем итүче Хаким Пакьтер. Ий Рамазан ае, синең белән саубуллашабыз, саубуллашабыз, аерылабыз, аерылабыз. Мәңге, Хәким, Галим булган Аллаһы, безнең гөнаһларны ярлыка, Син юмартлык Иясе, гөнаһларны Ярлыкаучы, ий Рәхимнәрнең Рәхимлесе.**

Мәчетләрне тәравих белән бизик

Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәлам: «Рамазан аенда, бу айның изге ай икәнлегенә ышанган хәлдә һәм әҗер-савабын бары тик Аллаһыдан гына өмет итеп тәравих намазын кылучыга аның барлык элеккеге гөнаһлары кичерелә», – дип әйткән. Шулай ук ул: «Аллаһы Рамазан аенда ураза тотуны сезнең өчен бурыч иткән. Ә мин исә аның төнендә кыямда торуны, ягъни тәравих намазын сөннәт иттем. Кем иманлы йөрәк белән, савап алу теләге белән Рамазан аенда ураза тотса һәм тәравих намазын укыса, гөнаһлардан котылыр, яңа туган сабый бала сыман булыр», – дип әйткән.

ИГЪТИКЯФ

Рамазан аеның ахыргы ун көнендә ир-атларга бер тәүлек булса да мәчеттә кунып, ә хатын-кызларга өйләрендәге намаз укый торган җирләрендә игътикяф кылу – сөннәт. «Игътикяф» сүзе берәр изге саналган урыннан (мәчеттән) чыкмый күпмедер вакыт гыйбадәт кылу дигәнне аңлата.

Галинең улы Хөсәен радыяллаһу тапшырганча, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам әйткән: «Рамазан аенда ун көн игътикяф кылган һәр кеше ике хаҗ һәм ике гомрә хаҗы кылган кебек булыр».

Имам Бәйһакый Хәсән радыяллаһу ганһедән тапшырганча: «Игътикяфтә булган кешегә һәр көне өчен бер хаҗ савабы бирелә».

Игътикяфтәге кешеләр мәчеттә намаз, Коръән укыйлар, гыйлем өйрәтәләр һәм өйрәнәләр, зикер, тәсбихләр әйтәләр, китаплар укып, дини мәсьәләләр турында сөйләшеп утыралар. Аларга мәчеттә дөнья эшләрен башкару һәм дөнья мәшәкатьләре турында сөйләшү мәкруһ санала.

Игътикяфнең шартлары

1. Ният әйтү.

Кеше ният әйтмичә игътикяф кылса, дөрес булмас.

2. Җәмәгать мәчете.

Игътикяфне азан һәм камәт әйтелә торган һәр мәчеттә кылу дөрес булыр. Хатын-кыз өендәге намаз укый торган бүлмәсендә игътикяф кыла. Ирләр өчен җәмәгать мәчетенең хөкеме ничек булса, хатыннар өчен өйдә даими намаз кыла торган урынның хөкеме дә шулай.

3. Ураза.

Ураза – игътикяфнең бер шарты, чөнки Гайшә радыяллаһу ганһә: «Уразасыз игътикяф булмас», – дип әйткән. Бер кеше бер ай буе ураза тотмыйча гына игътикяф кылуны үз өстенә алса (вәгъдә итсә), бу кешенең бер ай буе ураза тотып, игътикяф кылуы кирәк булыр, чөнки вәҗиб игътикяф уразасыз кабул булмас. Вәҗиб игътикяфтә уразаның тотылуы шарт.

4. Сәламәт акыллы булу.

Акылга зәгыйфь кешеләр ният әйтә алмый.

5. Җөнеблек, күрем һәм нифастан (бала тапканнан соң килә торган каннан) чистарыну.

Җөнеб булган кешегә, күремле яки нифаслы хатын-кызга мәчеткә керү тыела.

– Балигъ булу шарт түгел.

– Ир кеше яки азат булу да шарт түгел.

– Хатын-кыз, әгәр кияүгә чыккан булса, игътикяфне иренең ризалыгы белән генә кылыр. Ире рөхсәт итеп, хатыны шушы рөхсәт белән игътикяф кылса, ире аны игътикяфтән тыя алмас. Әгәр тыя икән, бу тыюы дөрес булмас.

Игътикяфне бозган һәм бозмаган нәрсәләр

Игътикяф кылучы ирләр мәчеттә ашыйлар, эчәләр һәм йоклыйлар. Аларга бәдрәфкә бару, тәһарәт алу кебек мәчеттә үтәү мөмкин булмаган эшләр һәм аш-су алып килү өчен генә мәчеттән чыгу рөхсәт ителә.

– Әгәр сәбәпсез дөнья эше өчен мәчеттән чыгып, алты сәгать вакытын читтә үткәрсә, игътикяф бозыла. Хатын-кыз өендә игътикяф кыла торган бүлмәсеннән өйгә чыга алмый. Хатын игътикяфне мәчеттә кыла торган булып, ире аны кайтырга чакырса, өенә кайтып, игътикяфен шунда дәвам итәргә тиеш.

– Игътикяф кылучы кеше госел һәм тәһарәт алу өчен мәчеттән чыга ала. Ләкин бу ихтыяҗларын үтәүгә үк кире мәчеткә керергә тиеш.

– Мәчетнең ишелүе куркынычы янаганда яки шуңа охшаш башка сәбәпләр булганда гына мәчеттән чыгу тиешле.

– Игътикяф кылучы кеше хастаның хәлен белергә яки җеназа намазына катнашу өчен мәчеттән чыга торган булса, игътикяфе бозыла. Хасталыгы сәбәпле, мәчеттән тышка чыгуы да игътикяфне боза. Ләкин игътикяф кылырга нәзер әйтеп, хастаның хәлен белү, җеназа намазына катнашу яки гыйлем мәҗлесенә әзерләнү өчен мәчеттән чыгу шартын да кушса, игътикяфе бозылмый.

■ **Сәхифәне Гәбделхәким Фәсхиев әзерләде**

«Әр-Рәхман» сүрәсендәге кайбер нигъмәтләр

«Әр-Рәхман» – Коръәни Кәримнең 55 нче сүрәсе. Рәхимле Зат – Аллаһы Тәгалә – бу сүрәдә Үзенең колларына биргән бик күп нигъмәтләрне искә ала һәм шуннан соң еш кына: «Ий, кеше вә җен, Раббыгызның кайсы нигъмәтләрен ялган дип саный аласыз?» – дип сорау бирә. Бүгенге мәкаләбездә дә шул нигъмәтләрне өйрәнүне дәвам итәрбез.

Адәм галәйһиссәламнең барлыкка килүе

Адәм галәйһиссәлам – беренче кеше. Шуңа да без аны «атабыз Адәм» дип атыйбыз. Адәм галәйһиссәлам беренче пәйгамбәр дә булып тора. Гомер озынлыгы да 930 ел. Ә аның барлыкка килүе турында Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

«Ул (Аллаһы Тәгалә) кешене янган кирпеч кебек кипкән, чыңлап торган балчыктан (яшәү әсәре булмаган каты туфрактан) яратты».

«Әр-Рәхман / Рәхимле», 55:14

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам болай дип әйткән: «Фәрештәләр нурдан яратылганнар, җеннәр – чиста уттан (ялкыннан), ә Адәм галәйһиссәлам сезгә тасвирланган нәрсәдән». Галимнәр «сезгә тасвирланган нәрсәдән» дигән сүзне шушы аять белән аңлаталар, ягъни яндырылганга охшаган, чыңлап тора торган балчыктан.

Моның турында Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримнең башка сүрәләрендә дә искә ала. Мәсәлән, «Мөэминнәр» сүрәсендә Ул: «Һичшиксез, Без кешене саф балчыктан яраттык», – дип әйтә. Ә «Рум» сүрәсендә: «Дәхи Аллаһының кодрәтенә дәлил булып торган нәрсәләрнең берсе – Ул асылыгыз Адәмне туфрактан халык итте, соңрак сез кешелек дөньясы булып, җир йөзенә таралдыгыз», – дип әйтелә.

Чыннан да, кешелек дөньясы Җир шарының бер генә урынында тупланып яшәми. Алар материк, утраулар буенча чәчелеп беткәннәр. Без күп, без төрле. Әмма ничек кенә булмасын, кешеләрдә гомум сыйфатлар бар: яхшы, начар, рәхимле, эчкерсез һ.б. Моның турында Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам дә: «Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә Адәмне Җир шары буенча җыйган бер уч балчыктан яратты. Адәм балалары да шуңа охшаган булып бар булдылар. Алар арасында кызыл, ак, кара һәм аларга охшаш төстәгеләр бар. Шулай ук начарлары, яхшылары һәм алар арасындагылар да бар», – дип әйткән.

Шулай итеп, кешенең барлыкка килү асылы – җирдән, калган кешеләр – галәктән, ягъни оешкан каннан. Бала ана карынында формалаша, шунда ук аңа җан иңә. Туганда көчсез булып туса да, үсә-үсә көчәя. Шәһәрләр, күперләр салырлык акыл, көч белән бүләкләнелә. Боларның һәрберсен дә кешегә Аллаһы Тәгалә биргәнен генә онытмаска кирәк.

Җеннәрнең килеп чыгышы

«Дәхи, җенне уттан булган ялкыннан халык кылды».

«Әр-Рәхман / Рәхимле», 55:15

Кешенең барлыкка килү асылы җир булса, җеннәрнең иң беренче булып яратылганы – Иблис– уттан бар кылынган. Коръәнне тәфсир кылучы сәхабәләр, галимнәр аны төтенсез саф ут дип әйтәләр.

Кешелекнең җеннәрдән булган өстенлеге – җирдән барлыкка килү. Җир – үсемлекләр үсәр өчен мөһим бер шарт булып тора. Гомумән, җир бик күп нигъмәтләргә бай, ә ут – явызлык, начарлык, ахмаклык һәм зур зыян чыганагы.

Кешеләрнең һәм җеннәрнең барлыкка килүләре үзе бер дәрес, гыйбрәт булып тора. Шушы ике аятьтән соң Аллаһы Тәгалә кабаттан: Ий, кеше вә җен, Раббыгызның кайсы нигъмәтләрен ялган дип саный аласыз?» – дип сорау бирә.

Көнчыгыш һәм көнбатыш нигъмәтләре

Аллаһы Тәгалә «Әр-Рәхман» сүрәсен дәвам итеп: «Ике көнчыгышның һәм ике көнбатышның Раббысы», – дип әйтә.

«Ике көнчыгышның һәм ике көнбатышның» дигән өлешне болай дип аңларга кирәк: кояш җәй көне һәм кыш көне төрле җирләрдән чыга һәм төрле җирләрдә бата. Әмма алар барысы да Аллаһы Тәгаләгә буйсына. Кышларын Аллаһы Тәгалә кояшны соңрак чыгарып, иртәрәк батыра, ә җәйләрен иртәрәк чыгарып, соңрак батыра. Кыш көне кеше үзен хәлсезрәк итеп хис итә, ә җәй көне ул кичке 9 ларга кадәр эшләсә дә, армый.

Бу система табигатькә дә, җәнлекләргә дә, кешелеккә дә зур файда бирә. Аллаһы Тәгалә җир шарында һәрвакыт кояш кына, яки караңгы төн генә булып тора торган итеп ясый ала, әмма алай бөтен мәхлүкат арыр иде. Аллаһы Тәгалә «Ән-Нәба» сүрәсендә:

«Дәхи төнне сезгә пәрдә кылдык. Дәхи көндезне тереклегегез өчен кәсеп кылырга якты кылдык», – дип әйтә. Ел фасыллары алышыну, җирнең үз күчәре тирәли әйләнеп, көн һәм төн алышынуы – боларның барысында да зур хикмәт бар.

Җирнең үз күчәре һәм Кояш тирәли әйләнеп йөрүе бик катлаулы процесс. Әмма Аллаһы Тәгалә моны кешеләрне барлыкка китерү белән чагыштырып: «Җир вә күкләрне яраткан Аллаһы, кешеләр кебек кечкенә нәрсәләрне халык кылырга кадир түгелме? Әлбәттә кадир, вә Ул Яратучы һәм Белүчедер. Аллаһы бер нәрсәнең бар булуын теләсә, ул нәрсәгә фәкать «Бул» дип әйтер һәм ул нәрсә бар булыр».

Димәк, көн саен иртәләрен кояш чыкканда һәм кичләрен кояш батканда без Аллаһының зур нигъмәтен күрә алабыз икән. Һәр баткан кояш – үзе белән бер көнне алып китә, димәк, гомеребезнең бер кисәге китә. Бу да Аллаһының бер рәхмәте, бер нигъмәте.

Ике агым хикмәте

Кешелек тормышы һәрвакыт күк, океан-диңгез белән кызыксынып яшәгән. 1962 елларда диңгездә яңа ачылышлар ясалды. Шуларның берсе – диңгездә булган ике агым.

«Аллаһы берсе төче, берсе тозлы ике диңгезне янәшә агызды. Аларның арасында Аллаһының кодрәт пәрдәсе бардыр: сулары кушылмас».

«Әр-Рәхман / Рәхимле», 55:19-20

Ибне Зәйд моның турында: «Аллаһы Тәгалә аларга бер-берсе белән кушылмас өчен, аерып тора торган киртә урнаштырды», – дип әйтте. «Әл-Фуркан» сүрәсендә дә Аллаһы Тәгалә: «Ул – Аллаһы ике зур суны янәшә агызды, ул суларның берсе эчәргә тәмледер, икенчесе эчәргә ачы, тозлыдыр, вә алар арасына пәрдә кылды вә бергә кушылудан тыя торган яшерен көчне араларына куйды», – дип әйтә.

Табигатькә төче суның да, тозлы суның да файдалары бихисап. Елгаларда төче су ага. Әмма алар тозлы диңгезләргә дә кушылалар. Галимнәр фикеренчә, файдалары төрле булганга да, Аллаһы Тәгалә аларны аерып куйган.

Аллаһы Тәгалә төче суны «эчәргә тәмледер» дип бирә. Ул су – елга, чишмә, кое сулары. Икенчесе – тозлыдыр, ягъни эчәргә яраксыз су. Бу сулар барыбызга да яхшы таныш океан һәм диңгезләрдер: Тын океан, Һинд океаны, Атлантик океан, Кызыл һәм Кара диңгез һәм башкалар. Бу сулар акмыйлар, әмма алар дулкынлана, давыллана. Айның артуына һәм кимүенә карап, аларда күтәрелеш һәм чигенешләр була. Һәм бу күренешне Аллаһы Тәгалә барлык тик тора торган суларга урнаштырды.

Тозлы булганга ул су бозылмый, анда һәлак булган балыклар бозылып, начар ис чыгармый. Диңгездән искән җил һәрвакыт саф, ә анда үлгән балыклар ашарга яраклы була. Шуңа да Пәйгамбәребез галәйһиссәламнән диңгез суы белән тәһарәт алу турында сорагач, ул: «Диңгез суы пакь, ә анда һәлак булган балыклар ашарга яраклы»,– дип җавап кайтара.

■ **Сәхифәне Ленар Хамматов әзерләде**

Рамазан аенда кылына торган хаталар

Рамазан аен зарыгып көтеп алабыз, әмма ул үтеп киткәндә һәрберебез дә бер үк төрле хисләрне кичерәбез микән? Рамазан олуг нигъмәтләр ае булуга карамастан, барлык кеше дә алар белән нигъмәтләнә алмый? Ни өчен? Чөнки Рамазан аенда үзебезне ничек тотасын, кайсы гамәлләрне күбрәк кылырга, ә кайсыларыннан читләшергә икәнлеген белмәскә дә мөмкинбез. Бу Рамазан аебыз уңышлы һәм бәрәкәтле үтсен дигән ният белән, түбәндәге язманы әзерләргә булдык. Чыннан да, Рамазанда да, калган көннәрдә дә без хаталанырга мөмкинбез, бу гадәти хәл. Шуңа да искә төшереп китү ниятеннән, Рамазан аенда кылырга мөмкин булган кайбер хаталар турында сөйләшеп китик.

Ураза тотмау



Беренче хата булып Рамазан аенда ураза тотмау тора. Ни өчен? Чөнки ул фарыз гайн дәрәҗәсендәге гамәл. Ислам динендә фарыз гамәлләр бар икәнен беләбез, шуңа күрә аларны калдыру – Аллаһы каршында гөнаһлы булу дигәнне аңлата. Кем дә кем Аллаһы Тәгаләгә ышана, фарызларны таный икән – аңа акрынлап аларны үти башларга кирәк. Шулай булганда, Кыямәт көнендә фарыз кылынган гамәлләр өчен соралганда, җавап бирү җиңел булыр. Аннан соң, безнең күпме сәламәтлекләре зәгыйфь булган дусларыбыз бар. Алар теләсәләр дә, ураза тота алмыйлар. Без Аллаһыга шөкер кылып, гыйбадәтләребезне башкарырга тиешбез.

Ризык турында гына уйлау

Икенчесе – Рамазан аенда барлык игътибарны бары тик ризыкка гына юнәлтү. Күп еллар ураза тоткан кешеләр алдарга мөмкинлек тә, ирек тә бирмәсләр: авыз ачканда кеше кайчан туена? Дөрес, су эчеп куйгач та. Инде ахшам намазыннан соң бер тәлинкә аш ашаганнан соң, ашказаны башка ризыкны сорамый да. Әмма Рамазан аен: «Бүген ифтарга нәрсәләр әзерлим икән?» – дип кенә үткәрсәк, без аны шул ашау өчен генә көткән кебек булабыз. Моңа да игътибар итсәк иде. Ә инде тәмле ризыклар көненә килгәндә, ул бар – Ураза гаете бәйрәме. Менә аны чын бәйрәм итеп, дуслар-туганнар бергә җыелып билгеләп үтүне гадәткә кертсәк була, чөнки ул мөселманнарның рәсми бәйрәме булып санала.

Күп еллар ураза тотып та, намаз турында уйламау



Пәйгамбәребезнең бер хәдисендә: «Кыямәт көнендә иң беренче соралачак нәрсә – ул намаз», – дип әйтелә. Иң яхшы ысул – акрынлап җомга намазларына йөри башлау. Шуңа күрә моңа да игътибарлы булсак иде. «Әл-Бәкара» сүрәсенең 208нче аятендә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

«Ий иман китерүчеләр! Әмерләремә итагать итегез һәм Исламга тулысынча керегез». Ислам диненең 5 рөкенгә нигезләнгәнен барыбыз да бик яхшы белә. Шуларның берсе – намаз. Пәйгамбәребез дә галәйһиссәлам: «Кыямәт көнендә иң беренче соралачак нәрсә – ул намаз», – дип әйтеп калдырган. Бу исә намаз укуның Исламдагы әһәмиятен, аның югары дәрәҗәсен күрсәтеп тора. Диннең бер өлешен кабул иткәнбез икән, акрынлап калган вазифаларны үти башларга кирәк, чөнки Аллаһы Тәгалә дә: «Исламга тулысынча керегез», – дип әйтте.

Коръән укымау

شَهْرُ رَمَضَانَ الَّذِي أُنزِلَ فِيهِ الْقُرْآنُ
هُدًى لِّلنَّاسِ وَبَيِّنَاتٍ مِّنَ الْهُدَىٰ وَالْفُرْقَانِ

﴿١٨٥﴾



«Рамазан ае – бик шәрифле ай, ул айда Аллаһыдан кешеләргә туры юлны күрсәтә һәм һидаятьне ачык бәян кыла торган Коръән иңдерелде».

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:185

Коръәни Кәрим – Аллаһы Тәгаләнең сүзе. Без исә Аллаһы Тәгалә безгә нәрсәне кушкан, нәрсәне тыйган икәнен белергә, Коръәни Кәримне нинди максат белән иңдергәнен аңларга тырышырга тиешбез. Гарәп телен белмәсәк тә, укый белсәк – Коръәнне гарәп телендә укырга тырышырга, аның аятьләре нәрсә аңлатканын тәфсирләрдән карарга тиешбез. Коръән Пәйгамбәребезгә бирелгән иң зур могҗиза, ул могҗиза бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән, безнең дә аның белән танышу мөмкинчелегебез бар. Бу бәхет түгелмени? Шуңа күрә, Рамазан аенда булса да, бу китапка тагын да күбрәк игътибар итәргә тиешбездер.

Шулай ук Коръән уку өчен дә савап язылганын һәм бер хәреф өчен 10 әҗер-савап язылганын онытмыйк. Рамазан аенда гамәлләр өчен саваплар арттырылып языла, шунлыктан Коръән укып кына да бик күп саваплларга ирешергә мөмкин. Пәйгамбәребез дә: «Әлиф – бер хәреф, ләм – бер хәреф, мим – бер хәреф», – дип әйтеп, безнең Коръәнгә карата булган мәхәббәтебезне арттырырга тырышты.

Вакытны бушка сарыф итү

Югарыда Рамазан ае бик фазыйләтле ай дип әйтеп үттек. Шуңа күрә бу айдан файдаланып калмау гөнаһ булмаса да, хата саналыр. Бу дөньяда изгелек кылуга караганда, гөнаһ җыю җиңелрәк килеп чыга. Менә шуңа күрә Аллаһы Тәгалә бүләк иткән һәр форсаттан файдалана белергә тиешбез: Рамазан һәм башка шундый кичәләрдә изгелекләрне күбрәк эшләп калырга ашкынырга кирәк. Сәхәр ашагач, ифтарга кадәр йоклап яту, яки кирәксез гамәлләргә вакытны сарыф итү – әлбәттә, хатадыр. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә искә төшереп: **«Ураза санаулы көннәр», – дип әйтә.**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:184

Чыннан да, Рамазан ае нибары 29-30 көн генә. Боларның кадерен белсәк иде: Рамазан аенда кылган бер изге гамәл калган айларда кылган гамәлгә тиң түгел. Аның әҗер-савабы бик күп тапкыр артык языла.

Ураза тотуны ябыгу максату белән тоту

Рамазан ае уразасын диета белән бутарга һич ярамый. Кайбер кешеләр: «Уразада бераз ябыгып китәрмен, бераз матураеп китәрмен», – дигән ният куярга мөмкиннәр. Әмма бу хакыйкатькә туры килми, чөнки максатыбыз, ниятебез дөрес түгел. Чыннан да, ураза тоту сәламәтлеккә бик файдалы, шуңа да табиблар уразаны тотарга кушалар: монда барысы да ниятебездән тора. Пәйгамбәребез дә: «Һәрбер гамәл нияткә карап билгеләнә», – дип әйтте. Без ниятләребезне Рамазаен ае кергәнче үк дөресләргә тиешбез. Аллаһы Тәгаләнең әмерен үтим, Аңа якынрак булыйм дип, без бу гыйбадәтебезне башкарып чыгарга тырышырга тиешбез. Ә инде авырлыгыбыз артамы, кимиме – монысы безнең максат булырга тиеш түгел.

Рамазанда гына үзгәреп тору

Рамазан ае – бер ел буена рухи азык бирерлек ай. Шуңа да бу айда алган дәресләр, рухи тынычлыгыбыз безнең белән икенче Рамазанга кадәр булса иде. Кайберләребез Рамазан ае җиткәч кенә барлык гөнаһлардан тыелып, изге гамәлләргә басым ясыйбыз. Рамазанда булган халәт ел дәвамына җитсә иде: Рамазаннан соң да Коръән укуны, нәфел намазлар укуны дәвам итик; авыз ачуларга йөргән кебек, берберебезгә кунакларга йөрешү гадәтен ташламыйк.

Мәкаләбезнең ахырында Рамазан аена карата бер киңәш бирәсе килә: Кадер кичәсен эзләгез. Соңгы 10 көндә, көн саен 10 гына сум булса да садака бирегез, ике генә рәкагать булса да намаз укыгыз һәм 3 тапкыр «Ихлас» сүрәсен укыгыз. Әгәр сездә йөз сум гына булып, аны бер көндә садака итеп бирсәгез, Кадер киченә туры килмәскә мөмкин. Ә 10 сумлап биреп барсагыз, бу кичне тоту мөмкинлеге арта. Шулай ук «Ихлас» сүрәсен 3 тапкыр уку – бөтен Коръәнне укуга тиң. Бер генә көнне эзләп, аннан да колак какканчы, бу рәвешле гамәл кылу Кадер киченә эләгергә мөмкинчелек бирәчәк.

■ **Лилия Хәлефетдинова**

Ураза хөкемнәре

Түбәндәге өч төрле эш уразаны боза:

1. Борчак кадәр генә булса да берәр ризык яки дару йоту.
2. Бер тамчы кадәр генә булса да су яки дару йоту.
3. Якынлык кылу.

Ураза тоткан кешегә түбәндәге эшләр мөстәхәб (мактаулы гамәлләр) булып санала:

1. Таң атканчы, төнлә торып сәхәр ашау.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: «Таң алдыннан сәхәр ашагыз, чөнки бу вакытта бәрәкәт бар».

2. Авыз ачуны соңга калдырмау.
3. Изге гамәл-гыйбадәтләрне арттыру.
4. Изге Коръәнне уку, зикер һәм салават әйтү.

Җәбраил галәйһиссәлам, Рамазан аеның һәр төнендә Пәйгамбәребез белән очрашып, аның белән бергә Коръән укыган.

Ураза вакытында көндезен түбәндәге эшләрне кылу мәкруһ (шелтәле) санала:

1. Файдасыз һәм әдәпсез сүзләр сөйләү.
2. Ризык һәм сагыз чәйнәү.
3. Берәр азыкка телне тидереп татып карау.
4. Авыздан үбү.
5. Ифтар кылмыйча, ике көн рәттән ураза тоту.
6. Авыруның артачагын белә торып ураза тоту.
7. Сатып алыначак малны татып карау.

Ураза тоткан кешегә түбәндәге эшләрне башкару дөрес санала:

1. Балага ризык чәйнәп бирү (баланың ризыкны башкача кабул итү мөмкинлеге булмаганда).
2. Күзгә сөрмә тарту.
3. Тәһарәт вакытында мисвәк белән тешләрне пакьләү (әмма чистарткан вакытта мисвәктән бүленеп чыккан сок белән төкерекне һәм мисвәкнең кисәкләрен йотарга ярамый).
4. Кан алдыру.
5. Сөлек салдыру.
6. Госел коену.

Ураза кәффарәте

Рамазан уразасын үз ихтыяры белән бозган кешегә һәркөн урынына бер көн каза кылу һәм бозган өчен кәффарәт кылу фарыз була.

Ураза кәффарәте өчен 60 көн тоташтан ураза тоту тиеш була. Әгәр дә зәгыйфьлек сәбәпле 60 көн ураза тотарга куәт җитмәсә, 60 фәкыйрьне туярлык итеп ашату кирәк була.

Ураза тоткан кеше хаталык белән бераз



аш яки су йотса, бугазына кар яки яңгыр тамчылары керсә, ихтыяры белән авызын тутырып косса; таң аткан булса да, таң атмаган дип белеп сәхәр ашаса, кояш батмаган булса да, кояш баткан дип белеп авыз ачса яки якынлыктан башка җөнеб (госелсез) булса, уразасы бозыла. Андый кешегә Рамазан ае үткәннән соң уразасын каза кылу тиешле була, ә кәффарәт тиеш түгел.

Кайбер хөкемнәр

Бер кешенең бугазына тузан, туфрак, йон, төтен керсә; бер кеше төкреген, какрыгын яки теш арасында калган ризык кисәген йотса; уразалы икәнен онытып ашап-эчсә яки якынлык кылса, ул кешенең уразасы бозылмый.

Хәез һәм нифас белән гозерле булган хатыннарга ураза тоту дөрес түгел. Алар Рамазан аенда тотылмый калган уразаларын Рамазаннан соң каза кылырга тиешләр.

Ураза тотарга көче җитмәгән бик зәгыйфь, карт кеше ураза тотмаса, һәркөннең уразасы урынына бер фәкыйрьне туярлык итеп ашатырга яки ризык алырга җитәрлек акча бирергә тиеш була. Әгәр Рамазан аеннан соң шул карт сәламәтләнсә, калган уразаларын каза кылырга тиеш.

Йөкле яки бала имезә торган хатыннар, ураза тоткан вакытта, үзләренә яки балаларына зыян килүдән һәм хаста кешеләр үзләренең авырулары көчәюдән курыксалар, ураза тотмасалар да дөрес була. Аларның һәркайсы калган уразаларын Рамазаннан соң каза кылырга тиеш була.

Рамазан аенда мосафир булган кешегә дә ураза тотмау рөхсәт ителә. Сәфәреннән кайткач, аңа да калган уразаларын каза кылырга кирәк.

Таң атканнан соң сәфәргә чыккан кешегә мосафир булдым дип, уразасын бозу ярамый. Әгәр бозса, каза кылырга тиеш була.

Тотылмый калган уразаларын сәламәт вакытта каза кылып бетермәгән кеше авырып китсә, варисларына аның тотмый калган уразалары өчен фидия бирүне васыять итеп әйтүе – вәҗиб.

Әгәр шундый васыять әйткән кеше вафат булса, варисларына калган малының өчтән бер өлешеннән фидия бирү – вәҗиб.

Кадер киче

Рамазан аенда мөселманнарга зур бер бүләк бирелгән – ул Кадер киче. Бу кичәдә әҗер-саваплар бергә – мең бәрабәрендә языла. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйткән:

«Хактыр ки, Без Коръәнне Кадер кичендә төшердек. Сиңа Кадер киче дигәне нәрсәне белдерә? Кадер киче – мең айдан да хәерлерәктер. Ул кичтә һәртөрле эш өчен Раббыларының рөхсәте белән фәрештәләр һәм Җәбраил галәйһиссәлам иңәр. Ул төннең таңына кадәр иминлек, сәламәтлек булыр».

«Кадер / Кадер Киче», 97:1-5

Ни өчен соң ул төн «Кадер киче» дип аталды?

Кадер – ул «кодрәт», бу төн Аллаһы каршында иң кодрәтле һәм иң хөрмәтле төндер. Кадер төнен Коръән иңү белән үзенчәлекле иткән Аллаһы ул төннең тагын бер өстенлеген бәян итеп: «Кадер төне мең айдан хәерлерәк», – дип әйтә. Ул төнне догада, гыйбадәттә, зикердә, намазда үткәргән бәндә мең ай гыйбадәт кылудан да зуррак әҗер алачактыр.

Ул төндә җир йөзенә Җәбраил галәйһиссәлам һәм башка фәрештәләр төшәләр. «Ул таң беленгәнче иминлектер», ягъни Кадер төнендә җир өстенә төшкән фәрештәләр бәрәкәт, тыныч лык һәм хәерлелек белән төшәләр. Бигрәк тә ул фәрештәләр Коръән укучылар, Аллаһыны зикер итүчеләр һәм гыйлем эстәүчеләр белән бергә булалар. Шәйтан да ул төнне үзенең мәкерлекләрен кыла алмый.

Кадер төне кайчан була?

Мөселманнар өчен айлар арасында Рамазан ае, көннәр арасында җомга көне, кичләр арасында Кадер кичәсе иң мөбарәк санала. Кадер кичәсе Рамазан-шәриф аенда булган бер кичәдер. Шул ук вакытта Рамазанның кайсы кичәсендә булганы төгәл һәм анык рәвештә билгеләнмәгән. Бу мәсьәләдә галимнәр төрле фикердә.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Кадер төне –



Рамазанның ахыргы ун төнендә. Кем аларны уяу үткәрә, Аллаһы аның кылган һәм кылачак гөнаһларын кичерә. Бу да так санлы төндә: тугызынчы, жиденче, бишенче яки өченчесендә», – дип әйткән.

Кадер төненең билгеләре

Кадер төненең үз билгеләре бар. Галимнәр билгеләп үткәнчә, Кадер кичәсен кайбер галәмәтләрдән, шул кичкә хас булган аерым билгеләрдән тәгаенләргә мөмкин: бу кичә нурлы, тыныч һәм матур булыр; бик салкын да, бик эссе дә булмас; ул кичтә болытлар йөрмәс һәм җил исмәс, һавадан йолдызлар атылмас, яңгыр яумас, барча җиһанда тынлык урнашыр.

Кадер кичәсе гыйбадәте

Бу кичә Аллаһының рәхмәте бик мул булган бер кичәдер. Көндез ихтыяҗы булганнарга мөмкин кадәр ярдәм итәргә, авыз ачканда фәкыйрьләрне ашатып-эчертергә, кичен Коръән укып, гыйбадәт кылып үткәрергә кирәк. Гыйбадәттә каза намазын кылу, Коръәни Кәримнән сүрәләр, догалар уку, тәүбә итү, садака бирү, мөселманнарны сөендерү һәм башка саваплар казану – болар барысы да бу кичәгә хөрмәт күрсәтүнең ишарәседер. Хөрмәт күрсәтү гөнаһлы эшләрне эшләмәү белән дә хасил булыр.

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр берәү, Аллаһы Тәгаләгә инанып һәм савабына өметләнеп, Кадер кичәсен гыйбадәт кылып уздырса, элек кылган гөнаһлары гафу ителәчәк», – дип әйткән.

Аллаһы Тәгалә барчабызга да бу олуг нигъмәтләргә ирешергә насыйп әйләсә иде.

Сәхифәне Ленар Хамматов әзерләде

Имамның батырлыгы

Динмөхәммәтов Ишмөхәммәдкә багышлана

«Реальное время» интернет газета сайтыннан

Вятка губернасы, Малмыж өязендәге Түнтәр авылында имам вазифасын башкарган хәзрәтнең үлем җәзасына хөкем ителүенә 2019 елның 8 маенда 100 ел тула. Моннан бик күп еллар элек, шундый ук язгы көндә ул кулыннан Коръәнен ычкындырмыйча чокыр читендә торган.

Яңа заманның идеологиясен гәүдәләндергән чекистлар 70 яшьлек хәзрәткә: «Иманнан баш тарт! Коръәнне ташла! – сине исән калдырачакбыз», – дигән катгый таләпләр куялар. Әмма имам ныклык күрсәтеп, кулындагы Коръәнен күкрәгенә тагын да катырак кыса. Аның бу дөньядагы соңгы сүзләре дә – «Аллаһы бөек» дигән гыйбарә була. Аның гомере – батырлык иде, үлеме дә батырлыкка әйләнде.

Бу һәлакәтле көндә гомерләре өзелгән кешеләрнең саны 15 иде. Болар – якын-тирә авыл мәчетләрендә эшләгән 14 имам һәм бер христиан рухание. Шулай итеп, өяздәге бик зур хөрмәткә ия булган кешеләр бер кизәнүдә юк ителделәр. Әлбәттә, аларның фикер-карашлары яңа заман тенденцияләренә каршы килә иде, һәм хакимияттә булганнар бу фикерләрнең халыкка якын булуыннан, халыкны үзгәртә алуыннан курка иделәр. Бу 15 кешенең язмышы мәхкәмәнең хөкеменнән башка гына хәл ителә, шуңа да бу вәхшилек турында бернинди дә язмалар сакланып калмаган. Бу кешеләрең исемнәрен дә бары тик аларның туганнары гына хәтерлидер, әмма законсыз хөкем ителгәннәр арасындагы бер имамның исеме гасырлар буе сакланыр.

Үз заманының гына герое түгел

Үзе исән вакытта ук бөтен Рәсәй патшалыгына танылган була ул. Кайчандыр имам булып хезмәт иткән җирлекләрдә аны бүгенге көндә дә хөрмәт итәләр, истә тоталар. Аның исеме – Ишми ишан. Халык Ишми ишан дип Динмөхәммәтов Ишмөхәммәдне атап йөрткән. «Бик акыллы һәм намуслы әлеге имам – татарларның рухи чисталыклары өчен, әдәп-әхлагы өчен көрәшкән».

Бүгенге көндә Ишми ишанны кайбер кешеләр әдәби персонаж дип кенә белә, һәм аның чынлыкта да яшәгәненә бик шикләнеп карыйлар. Әмма бу алай түгел: ул татар халкының язмыш турында кайгыртып, гомере буе ислам традицияләрен саклап калу өчен тырыша. Хәзерге татар энциклопедиясендә ул XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы күренекле иҗтимагый һәм дини эшлеклесе, Рәсәйдә алдынгы кадимче булып саналган. Бүгенге көндә исә аның язмышын, эшләгән эшләрен өйрәнә башладылар. Аның турында: «Үз заманының мәшһүр иҗтимагый эшлеклесе, публицист, ортодоксаль ислам вәкиле буларак яңалыкка каршы көрәшүче», – дип тә язалар.

Түнтәр авылында яңа карашлы (җәдиди) мәдрәсә салынгач, Ишмөхәммәд Динмөхәммәтов үз мәхәлләсендә элек-электән килгән карашларны, исламның чисталыгын саклап калыр өчен, бик күп елларга сузылган көрәшкә аяк баса. Җәдитчелеккә карашлары турында ул 40 тан артык китап һәм брошюра яза. Кызганыч, әмма Ишмөхәммәд хәзрәт язган публицистик хезмәтләрнең күбесе әлегә өйрәнелмәгән, кайбер-ләре, гомумән, тикшерүчеләр өчен ачык түгел. Шуңа да карамастан, сакланып калган өлешләрдән дә Ишмөхәммәд хәзрәтнең кадими карашларны яклаучы көрәшче дип атап булыр иде. Аңа шушы хезмәтләре, һәм Ислам динен чисталыкта саклап калырга тырышуы өчен Ишми ишан дигән тәхәллүс тә бирәләр. Ул үзенең оппонентларының фикерләрен ти-рәнтен өйрәнә, анализлый. Үз карашларын ачык һәм дәлилләр белән раслап, аларны халыкның аңына кертү белән шөгыльләнә.

Ишмөхәммәд хәзрәт XX гасыр башында кайнап торган, буталып беткән татар тормышының үз юлын эзләү юлында актив катнаша. Ул җәдидиләр һәм кадимиләр бәрелешенең үзәгендә тора. Татар халкының язмышын йөрәгенә бик якын алганлыктан, аның якты киләчәге турында кайгыртуны үзенең бурычы итеп санаганлыктан, аны «Бөек мулла», «Олы ишан» дигән исем белән атый башлыйлар. Ишан хәзрәтнең бу бөеклеге кайдан килә, халыкның ышанычын ничек яулап ала соң ул?

Түнтәр авылы имамы бер генә вакыйганы да игътибарсыз калдырмаган. Барлык төр проблемаларны да өйрәнергә, аларны чишәргә тырышкан. Ул проблемалар төрле өлкәләргә карый алганнар: мәгариф, хатын-кызның җәмгыятьтәге хәле, яшүсмерләр тормышы, театр, сәламәтлекне саклау мәсьәләләре, иҗтимагый фикер юнәлешләре һәм башка шәхси, җәмгыяви мәсьәләләр.

Җәдиди һәм кадими карашлар

Узган гасыр башларында мөселман дөньясы ике тарафка: кадимчеләр һәм җәдидчеләргә бүленде. Ишмөхәммәд Динмөхәммәтов үз карашларында, ягъни кадимилектә калды. Әлбәттә, Ишми ишан җәдитчелеккә каршы түгел иде, ул күбрәк андагы хәзрәтләргә, аларның гасырлар буе сакланып килгән Ислам дине нигезләренә, шәргый кануннарга кертергә тырышкан яңалыкларга каршы иде.

Ишми ишан – гыйлем яраткан һәм тараткан

Балаларына яхшы дини белем бирергә теләгән һәрбер ата-ана Түнтәр авылына барган. Ишмөхәммәд хәзрәткә ышаныч зур булган, аның сүзенә һәрбер кеше колак салырга тырышкан. Җәдиди халкыннан аңа: «яңалык дошманы, элеккеге артталык кешесе» дигән исем бирелсә дә; аны катып калган, дини фанат дип йөртсәләр дә, Ишмөхәммәд хәзрәт фәндә булган яңа ачышларны, техника һәм сәнәгать үсешләрен бик хуплап каршы алган. Ул беркайчан да дөньяви гыйлемнәрне өйрәнүгә каршы бармаган. Бары тик дөньяви гыйлемнәрнең дини гыйлемнән соң булуын теләгән. Мәгърибнең (көнбатышның), ягъни рус мәдәниятенең татарларга йогынтысын хупламаса да, Ишмөхәммәд хәзрәт үз мәдрәсәсендә рус теле укытуга каршы булмаган, киресенә, ул үзара бәйләнештә яшәргә кирәк дип санаган. Башка тел өйрәнү – үзебезнең үзенчәлекне югалтмыйча, башка бер өлкәдә үсешне күз алдында тоткан, һәм бу тормышта бик мөһим урын алып торган.

Ишмәхәммәд хәзрәт мәдрәсәсендә мантыйк фәннәре кергән, шәкертләрне әңгәмәләр корырга өйрәткәннәр. Һәм шушы гамәлләрдән соң, әлбәттә: «Мәдрәсәдә шәкертләр 10 ел буе үзләре дә аңламый торган догаларны гына ятлап яталар», дигән сүзләрне ишетү бераз сәер дә.

Татар халкы тормышындагы югалмас эз

1909 елдан алып 1918 елга кадәр Ишмөхәммәд Динмөхәммәтов «Дин вә Мәгыйшәт» журналының актив язучы авторы була. Бу журналда аның 70 тән артык мәкаләсе басылып чыга. Мәкаләләрендә Ишми ишан киңәшләрен бирә, сорауларга җаваплар яза, Ислам диненең нигезләрен аңлатырга тырыша, фикерләрен яза, нәрсәнедер яклап чыга, нәрсәгәдер каршы төшә, кемнедер яклый, ә кемнедер, киресенчә, гаепләп чыга.

Ул телгә бик үткен булган. Бигрәк тә аның турында ялган мәгълүмат тарала башласа, аның теле тагын да шомара төшә, бертөрле зәһәрлелек хас булган.

Ишмөхәммәд хәзрәт ике диннең дә (Ислам һәм насара) дустанә яшәүләренә, ике мәдәниятнең янәшә атлауларына риза булган, әмма аларның бер-берсенә тәэсирен хупламаган. Ул Ислам динен төрле бидгать гамәлләрдән саклаган, диннең яңа заманга җайлашуына каршы булган. Ишми ишан кемгә генә каршы чыксса да, аларның хезмәтләрен тирәнтен өйрәнә торган булган, шуңа да аның әйткәннәре коры уйдырма гына булып калмаган.

Ишмөхәммәд Динмөхәммәтов татарларның милләт буларак үзбилгеләнүләре өчен көрәшмәгән. Киресенчә, ике халыкның дус булуын теләгән. Әмма мәчет-мәдрәсә эшенә чит кешеләрнең дә кысылуын хупламаган.

Дәүләтнең мәчет-мәдрәсә эшләренә кагылмавы татар халкының да тормышында зур роль уйный, чөнки бу дини руханилар эше генә булмыйча, гыйлем, мәдәният, тәрбия бирү, хатын-кызларның җәмгыятьтәге урыннары мәсьәләсенә кагыла торган була.

Ишми ишан гомере буе яшәп һәм хезмәт иткән җирлектә 2003 елда мәчет салынгач, мәхәллә халкы аңа Ишмөхәммәд исемен бирде. Шул рәвешле, халык имамга үзенең хөрмәтен һәм ихтирамын белдерде.

■ **Ишмөхәммәд Динмөхәммәтовның оныгының кызы Диләрә Мөхәммәдьярова**

Коръәндә искә алынган хәерле гамәлләр

Коръәндә «хәйр», ягъни яхшылык сүзе 176 аятьтә очрый. Ул аятьләрдә мөәмин-мөселманнар кыла торган хәерле гамәлләр турында искә алына. Шуларның кайберләрен карап үтик.

Намаз уку

Мөәмин кыла ала торган иң хәерле гамәлләр – Аллаһы Тәгаләгә якын гамәлләр, ягъни фарызлар. Исламның 5 терәге – 5 «сакчысы» бар. Кеше үзенең динен шушы 5 терәк белән саклап яши, ягъни Аллаһы Тәгаләнең барлыгын, берлеген таный, намаз укый, зәкят түли, ураза тота һәм хаҗ кыла.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә: «Кыямәт көнендә иң беренче сораачак нәрсә – намаз», – дип әйткән. Намаз уку иң хәерле гамәлләрнең берсе. Аның мөәмингә биргән бүләкләре санап бетергесез:

Беренчедән, **«Тәхкыйк, намаз фәхеш эштән, ярамаган эшләрдән укучыны тыя, намаз, әлбәттә, Аллаһы зекерләренең иң зурысы, Аллаһы сезнең ни эшләгәннәрегезне белә».**

«Гәнкәбут / Үрмәкүч», 29: 45

Икенчедән, Кыямәт көнендә намаз турында беренчеләрдән булып сораалыр, димәк, намазын торгызган кеше бу сорауны җиңел үтәчәк, ин шә Аллаһ.

Өченчедән, «Намаз – мөәминнең мигъраҗы», – дип әйткән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм.

Әлбәттә, намазның фазыйләтләре моның белән генә бетми, әмма аны кыла башлар өчен бу файдалар да мөһим этәргеч булып торалардыр.

Ураза тоту

Ураза, Рамазан турында Коръәни Кәримдә дә, Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисләрендә дә еш искә алына. Кодси хәдистә әйтелгәнчә: «Ураза – Минем өчен», ягъни Аллаһы Тәгаләнә өчен. Коръәндә намазны уку кирәклегенә басым ясалса, ураза турында Аллаһы Тәгалә Үзе дә аңлатып китә:

«Ураза санаулы көннәр. Сезләрдән берәрегез авырса, яки сәфәрдә булса, ураза тотмасын. Авыру кеше сәламәтләнгәч, сәфәрдәге кеше өенә кайткач, калган көннәрен бер көн өчен бер көн тотып тәмам итәр. Авырлык белән тотучыларга фидия тиеш. Берәү бер мөскен урынына күбрәк мескенне ашатса, артыгы үзенә хәерле. Әммә мескеннәрне ашатып, (уразаны) өстегездән төшерүгә караганда, ураза тотуыгыз сезнең өчен хәерле, әгәр белсәгез».

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:184

Рамазан ае якынлаша. Бу айда мөәмин-мөселман кыла торган хәерле гамәлләр бихисап, әмма иң фазыйләтләре булып барыбер 5 вакыт намаз һәм ураза торадыр. Кемдер: «Мин намаз укымыйм бит, ураза да тота алмыймдыр», – дип, уразасын калдырмасын: намаз – бер фарыз, ураза – аерым фарыз.

Ятимнәрне кайгырту

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтте:

«Янә синнән ятимнәр хакында сорашалар. Аларның барча эшләрен ислах кылу, юлга салу алар өчен хәерле, дип әйт. Әгәр ятимнәрне үз гаиләгезгә кушсагыз, алар сезнең кардәшләрегездер».

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:220

Ятимнәр сүзе Коръәни Кәримдә бик күп тапкыр очрый. Әгәр дә бу изге китапта берәр нәрсә күп тапкыр кабатланса, димәк, аңа зур игътибар итәргә кирәк. Аллаһы Тәгалә күп тапкырлар ятимнәрнең малын ашаучыларны кисәтә, аларга булышучыларны сөендереп, әҗер-савап вәгъдә итә.

Хәерлелек һәм начарлык белән сыналу

Бу дөнья Ахирәтнең кыры гына булып тора. Кеше басуда эшләгәндә хәерлелек килеп, матур кояшлы да, мул яңгырлы көннәре дә була, шулай ук озын-озак кояшлы гына. Яки уңышка зыян сала торган яңгырлы гына көннәр дә булгалый. Шуның кебек, бу тормышта кеше бик күп тапкыр сыналырга мөмкин. Әмма сыналу – бу яшәешнең асылы да булып тора. Иң күп сыналган кешеләр – пәйгамбәрләр. Әюб галәйһиссәламгә авыру иңә. Ибраһим галәйһиссәламгә баласы белән сынау килә. Могҗизаларны иң күбе Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм кыла, әмма кайгы-хәсрәтләр белән дә иң күбе ул сынала. Әмма пәйгамбәрләргә нинди генә сынау килсә дә, алар аны үтеп, югары дәрәҗәләргә күтәрел-деләр.

Шуның кебек, гади мөәмин дә көн саен нинди дә булса бер сынауга тап булып яши.

«Барча кеше үлем ачысын татучыдыр, Без сынау йөзеннән сезне сырхау, ачлык кебек яманлык илә; вә сәламәтлек, байлык кебек яхшылык белән сыныйбыз, яки савап белән гөнаһ арасында сезне сыныйбыз, соңрак хөкем ителергә Безгә кайтарылырсыз».

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:35

Гадел булу

Гаделлек – бу дөньяда бик кыйммәтле һәм кирәкле сыйфат.

«Дәхи үлчәгәндә үлчәүләрегез дөрес булсын, тигез үлчәгез вә дөрес үлчи торган гадел мизаннар белән үлчәгез! Гадел үлчәсәгез, үзегезгә хәерледер вә ахыры да күркәм булыр».

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:35

«Антларын, вәгъдәләрен бозмаган кешеләргә Ахирәттә Аллаһыдан биреләчәк нигъмәтләр, әлбәттә, хәерледер, әгәр белсәгез!»

«Нәхел / Умарта Кортлары», 16:95

Гаделлек төрле була ала:

1. Нинди дә булса гамәлдә гаделлек – үлчәгәндә, бәхәсләрне чишкәндә h.б.

2. Балаларга карата гаделлек. Балаларның үзләренә һәм аерым алганда – һәрберсенә. Бер сәхабә янына малае килгәч, аны үбеп, кызы килгәч, аны үпмичә генә янына утырта. Пәйгамбәребез моны күреп: «Син алар арасында гадел булмадың», – дип әйтә. Ибраһим Ән-Нәһагый: «Сәхабәләр балалары арасында аларны үбү санында да гадел иделәр», – дип әйтә.

Шулай ук эшче белән хуҗа арасында, ирнең хатынына карата, дусларга карата, үзеңнең туганнарыңа карата, казыйның хөкем ителүчеләргә карата да гаделлек сакланырга тиеш.

Кыямәт көнендә дә гаделлек турында соралачагын онытмаска кирәк.

Тәкъва булу

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтте: «... Тәхкыйк, сезнең Аллаһы хозурында хөрмәтлерәгегез – Аллаһыдан куркып гөнаһлардан сакланучыларыгыздыр, ягъни тәкъва булганыгыз...»

«Хүҗүрат / Бүлмәләр», 49:13

Һәртөрле изге гамәл кылу

Хәерле гамәлләрне санап бетергесез. Аллаһы Тәгалә кешеләргә дөньяда яшәү кануннарын аңлатканда, күпмедер гамәлне кылудан тыйды. Әмма шул тыйган гамәлләрдән кала башкалары йә мөбаһ, йә сөннәт, яйәмөстәхәб йә фарыз. Ягъни аларны кылудан кеше саваплы булачак. Садака бирү булсынмы, яхшы мөгамәлә кылу булсынмы, кемгә дә булса авыр хәленнән чыгу юлын күрсәтү булсынмы – болар барысы да яхшы һәм саваплы булып саналалар. **«Синнән Аллаһы ризалыгы өчен бирә торган садакалар хакында сорашалар. Син аларга: «Яхшы нәрсәләрегездән ата-аналарыгызга, якын кардәшләрегезгә, ятимнәргә, мескеннәргә һәм мосафирларга бирегез», – дип әйт.**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:220

Кеше яхшы гамәлләрне кылуны Аллаһы Тәгалә тыйган гамәлләрне калдырудан да башлый ала. Бу исә нинди дә булса изге гамәл кылуга караганда да саваплырак була ала. Бусага төбендә Рамазан ае, димәк, изгелекләрне арттыру, гөнаһларны калдыру өчен яхшы форсат. Әлбәттә, мәкаләдә кайбер хәерле гамәлләр генә искә алынды. Хәерлелекләр кылырга Аллаһы Тәгалә Үзе насыйп вә мияссәр кылса иде.

■ **Сәхифәне Гәбделхәким Фәсхиев әзерләде**



ТР мөселманнарының Диния нәзарәте һәм «Хозур» нәшрият йорты тарафыннан гарәп телендә «Исгафул муриддин лиикамәти әд-дин» дип аталган хезмәт нәшер ителде. Аның атамасын «Дин кануннарын үтәргә теләүчеләр өчен ярдәм» дип тәрҗемә итәргә мөмкин.

Хезмәтнең авторы – хәнәфи мәзһәбе, усул-фикһ галиме, мөхәддис, шәех Габделгани бине Талиб Әд-Димәшкый (рахимәһуЛлаһи). Китапта фикһ буенча төп, иң кирәкле мәгълүмат китерелгән, ул намаз, зәкят, фарыз ураза һәм хаҗ бүлекләреннән тора. Әлеге китап тормышын хак дин кануннарын өйрәнергә багышларга теләгән һәркемгә файдалы булыр.

Китапны «Хозур» нәшрият йорты кибетләрендә сатып алып була.

Адреслары:

- Казан, Тукай урамы, 36 йорт
- Газовая урамы, 14 йорт.

Белешмәләр өчен телефон:
+7 (903) 388-86-33.

VII РЕСПУБЛИКАКҮЛӘМ ИФТАР

Белешмәләр өчен телефон:
+7 (843) 237-86-18

ВОЛОНТЕР БУЛ!

Теркәлү өчен сылтама:
https://clck.ru/FReRL

25 май 2019 | «Казан-Арена»

КАЗАН ӨЧЕН МАЙ АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

Көн	Иртәнге намаз		Кояш чыга	Өйлә намазы	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ястү намазы
	Сәхәр тәмам	Мәчет-ләрдә укыла					
01.05.2019	00:46	02:31	04:01	12:00	16:52	19:21	21:44
02.05.2019	00:38	02:29	03:59	12:00	16:53	19:23	21:49
03.05.2019	00:28	02:27	03:57	12:00	16:54	19:25	21:53
04.05.2019	00:17	02:24	03:54	12:00	16:55	19:27	21:57
05.05.2019	00:02	02:22	03:52	12:00	16:57	19:29	20:59
Рамазан ае башлана!							
06.05.2019	01:50	02:20	03:50	12:00	16:58	19:31	21:01
07.05.2019	01:48	02:18	03:48	12:00	16:59	19:33	21:03
08.05.2019	01:46	02:16	03:46	12:00	17:00	19:35	21:05
09.05.2019	01:44	02:14	03:44	12:00	17:01	19:36	21:06
10.05.2019	01:42	02:12	03:42	12:00	17:02	19:38	21:08
11.05.2019	01:40	02:10	03:40	12:00	17:03	19:40	21:10
12.05.2019	01:38	02:08	03:38	12:00	17:05	19:42	21:12
13.05.2019	01:36	02:06	03:36	12:00	17:06	19:44	21:14
14.05.2019	01:34	02:04	03:34	12:00	17:07	19:46	21:16
15.05.2019	01:32	02:02	03:32	12:00	17:08	19:48	21:18
16.05.2019	01:30	02:00	03:30	12:00	17:09	19:50	21:20
17.05.2019	01:29	01:59	03:29	12:00	17:10	19:52	21:22
18.05.2019	01:27	01:57	03:27	12:00	17:11	19:53	21:23
19.05.2019	01:25	01:55	03:25	12:00	17:12	19:55	21:25
20.05.2019	01:23	01:53	03:23	12:00	17:13	19:57	21:27
21.05.2019	01:22	01:52	03:22	12:00	17:14	19:59	21:29
22.05.2019	01:20	01:50	03:20	12:00	17:15	20:00	21:30
23.05.2019	01:19	01:49	03:19	12:00	17:16	20:02	21:32
24.05.2019	01:17	01:47	03:17	12:00	17:17	20:04	21:34
25.05.2019	01:16	01:46	03:16	12:00	17:18	20:05	21:35
26.05.2019	01:14	01:44	03:14	12:00	17:18	20:07	21:37
27.05.2019	01:13	01:43	03:13	12:00	17:19	20:08	21:38
28.05.2019	01:12	01:42	03:12	12:00	17:20	20:10	21:40
29.05.2019	01:10	01:40	03:10	12:00	17:21	20:11	21:41
30.05.2019	01:09	01:39	03:09	12:00	17:22	20:13	21:43
31.05.2019	01:08	01:38	03:08	12:00	17:23	20:14	21:44

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
Апрель саны, №4 (285)

Баш мөхәррир: **Сәмигуллин К. И.**
Мөхәррир: **Шафикова Р. Р.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Сәйфетдияров Р. Г.**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
Электрон адресы: shura@huzur.ru
Телефон: +7 (843) 598-09-42

РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
Камил СӘМИГУЛЛИН;
«Хозур» нәшрият йорты директоры
Ришат ХӘМИДУЛЛИН;
ТР МДНнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе
Булат МӨБӘРӘКОВ;
Татарстанның баш казые
Җәлил ФАЗЛЫЕВ;
ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы
Габдулла ӘДҺӘМОВ

Гамәлгә куючы: Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
Нәшир: «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә Заказ №2748
Газетага ярты елга язылу бәясе – 132 сум. Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 23 нче апрельдә таратыла.
График буенча бу санга 22 нче апрель көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.